ШАНХАЙДА ОЧРАШУ

Татарстан Рәисе Кытайга эшлекле сәфәр кыла

> 2

БАБАЙЛАР МИРАСЫ

Болгарда татар дин әһелләре форумы узды

> 2

ФӘНИТ ХАРИСОВ:

«Татар телен кухня теле итеп калдырырга ярамый»

> 5

ИРЕК

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 71 (29038) | Сишәмбе | 23 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ОЛЫ ЮЛНЫҢ СЫНАВЫ

Бүген республика мәктәпләренең күбесендә соңгы кыңгырау чыңлый. Мәктәп белән саубуллашу гына түгел, олы тормыш башлану билгесе дә бу. Чыгарылыш укучылары тормышка әзерме?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Карандашым-китабым, узды китте елларым. Дәфтәрем һәм пеналым, сау булыгыз, дусларым». Укучылар үзләре дә, Илсөя Бәдретдинова җырындагыча, мәктәп елларының сизелмичә үтеп киткәнен әйтә. Бер яктан, күңел кыллары өзелергә торса, икенче яктан, алда мөстәкыйль тормыш көтә. Аңа кадәр әле имтиханнар тапшырасылары бар.

Актанышның сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат укучылары ел саен гаҗәпләндерергә ярата. Быел ни эшләргә җыеналар икән?

– Бу юлы тыныч кына үткәрергә булдык. Патриотик рухка өстенлек бирәбез, бердәмлекне күрсәтәчәкбез. Гимннардан башлыйбыз. Гимназиянең үзенеке дә бар, – ди 11 нче сыйныф җитәкчесе, география укытучысы Рөстәм Фәйзуллин. – Сыйныфымда – 16 укучы. Шуларның 14е БДИда информатика сынавын сайлады. Теләкләре – IT белгеч булу.

Гимназия-интернатны 37 егет һәм кыз тәмамлый. Алар Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләреннән, Сарман районыннан килеп укый. Күбесе Казан вузларына җыенса, берсе Санкт-Петербургка барырга ниятли икән.

Минзәлә районының Аю мәктәбен ике укучы тәмамлый. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Эльвира Фәррахова әйтүенчә, балалар аз, шуңа күрә әллә ни кызык тамашалар ясап булмый. Аларга ярдәмгә башка сыйныф укучылары килгән. Бергәләп шигырь сөйләп, җырлар җырлаячаклар. Укытучыларга, әти-әниләргә чәчәкләр бүләк итәчәкләр. «Бик моңсу вакыт. Күзләрдән яшьләр килә», – ди директор урынбасары.

Чирмешән районының Кармыш мәктәбен тәмамлаучылар – алтау. Алар вальс әйләнергә өйрәнгән. Сабый чактагы фотоларын куеп, газета чыгарганнар, саубуллашу стенды ясаганнар. Тантанадан соң теләкләр әйтеп, шарлар очырачаклар.

– Балалар бик актив, тырыш. Укуда да сынатмыйлар. Әти-әниләребез яшь. Алар белән барлык мәсьәләләрне бергәләп хәл итәбез, – ди сыйныф җитәкчесе Гөлия Гатина.

Сан

Быел Татарстанда **9** нчы сыйныфны – **41** меңнән артык, **11** нче сыйныфны **15** меңгә якын укучы тәмамлый.

Кайбыч районында 11 нче сыйныфны – 71, 9 нчы сыйныфны 157 укучы тәмамлый. Мәгариф идарәсе башлыгы Илмас Хәмидуллин фикеренчә, укучылар тормышка әзер.

– Заманына карап, балалар үзгәреп бара. Бөтенесе бертөрле була алмый. Кемдер хезмәт сөеп, кемдер иркәләнеп үсә. Кемдер китап укый. Бәлкем, фән өлкәсенә китәрләр. Бөтенесе дә авылга кайта, дип әйтеп булмый. Әти-әнисе эш яратса, бала да шуны күреп үсә. Студентлардан да күзәтергә була моны. Хәзер бит күбесе укый да, эшли дә. Акча табарга тырыша, – ди Илмас Хәмидуллин.

Ә Казан мәктәпләренең берсендәге әти-әниләр комитеты җитәкчесе Лилия Галимова әйтүенчә, балалар тормышка әзер түгел.

– Укучылар белән еш аралашам, фикерләрен сорашам. Укытучылар, БДИ бирә алмыйсыз, дип куркыталар икән. Шуңа күрә күбесе техникумнарга барырга мәҗбүр. Уку авыр, укыйсылары килми. Безнең сыйныфның яртысы мәктәптән китә. Минем кызым – отличник. Ул укуын 10 нчы сыйныфта дәвам иттерәчәк. Укыганда ук эшләүче егет-кызлар бар. Акча эшләү өчен баш кирәкми бит аңа, – ди Лилия Галимова.

Чыгарылыш укучыларында исә бәйрәм шатлыгыннан бигрәк, имтихан кайгысы. «Сынауларны укытучылар, әниләрнең йөзенә кызыллык китермичә, әйбәт кенә тапшырасы иде. Үзебез теләгән уку йортларына кереп, өметләребезне акларга язсын», – ди аларның күбесе.

Министр котлый

Илсур ҺАДИУЛЛИН,
Татарстан мәгариф һәм фән министры:

– Хөрмәтле чыгарылыш сыйныф укучылары, кадерле укучылар! Сез тиздән олы тормыш юлына аяк басасыз. Мәктәп еллары артта кала. Бу вакыт хәтерегездә мәңгегә калачак һәм сез беренче дәресләрегезне, беренче чын дусларыгызны, беренче җиңүләрегезне җылы итеп искә алырсыз. Укытучыларыгызны онытмагыз. Алар унбер ел буе сезнең өчен укытучы гына түгел, ә чын ярдәмче һәм киңәшче булырга тырышты.

Ышанам: сез үз алдыгызга зур юл һәм олы максатлар билгеләгәнсез. Бу юл гади булмаячак, ләкин ул мавыктыргыч, кызыклы һәм ачышларга бай булачак. Үз урыныгызны эзләгез, иң югары һәм кыю максатларны куярга курыкмагыз!

Безнең флот

Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасы флоты» акционерлык җәмгыятен булдыруга 2 миллиард сум юллаячак. Премьер-министр Алексей Песошин Хөкүмәтнең бу җәһәттән тиешле карарына кул куйган.

Компаниянең устав капиталы 100 проценты белән республиканыкы булачак. Карарда билгеләп үтелгәнчә, акционерлык җәмгыятен оештыруның төп максаты – су транспортында пассажирлар йөртүне үстерү.

Компанияне оештыруны Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыклары тәкъдим иткән. Карарның үтәлешен контрольдә тоту да нәкъ менә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләнгән.

Бетмәсен су

Климат җылыну сәбәпле, явым-төшемнең кимүе күздә тотыла. Шуңа күрә корылыклар ешрак булырга мөмкин. Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин республикада гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында шулай дип белдергән.

«Су хуҗалыгы өчен җаваплыларның барысына да суны идарә итү системасын яңадан карарга кирәк. Тиешле кисәтү чаралары вакытында күрелмәгән очракта, көтмәгәндә генә төче су запасы кимүдән гаять зур зыян килергә мөмкин», – дигән ул.

Утырышта коры үлән һәм чүп-чар яну очраклары еш килеп чыккан районнарны да атап үттеләр. Гадәттән тыш хәлләр министры Рафис Хәбибуллин әйтүенчә, исемлеккә Әлмәт (84 янгын очрагы – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 121 процентка арткан), Түбән Кама (156 очрак – 218 процентка арткан), Чирмешән (42 очрак – 281 процентка арткан), Зәй (47 очрак – 261 процентка арткан), Тукай (76 очрак – 171 процентка арткан) районнары кергән. Министр әйтүенчә, янгынга каршы көрәштә хакимият кенә түгел, халык та катнашырга тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кыздыра

Татарстанга антициклон үтеп керү сәбәпле, бу атнада көннән-көн эссерәк булачак. Явым-төшем көтелми. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 24 майда көндез һава температурасы +26…+31, төнлә +8…+17 градус чикләрендә тирбәләчәк. Пәнҗешәмбе – 25 май көнне тагын да эссерәк булачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +27…+32 градуска кадәр күтәреләчәк, төнлә +11…+19 градус күрсәтәчәк. Җомга – 26 майда да явым-төшемсез эссе һава саклана.

Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, 27–28 майда республикада һава температурасы акрынлап төшә башлаячак. Урыны белән яңгыр явачак.

Сүз уңаеннан, Татарстанда майның соңгы декадасында уртача һава температурасы нормадан 6 градуска югарырак булачак.

Нәтиҗә

Барасы як билгеле

РОССИЯ – ИСЛАМСКИЙ МИР KAZANFORUM

Җыен узды, эш дәвам итә. Татарстан башкаласында узган «Россия – Ислам дөньясы: «KazanForum»ның төп икътисадый нәтиҗәләрен соңрак җиткерергә вәгъдә иттеләр. Ничек кенә булмасын, санкцияләр шартларында кайсы юнәлештә юл тотачагыбыз хәзер үк билгеле. Бу хакта халыкара җыенда кат-кат әйттеләр. Форумда 80 ил вәкиле катнашты, 130 килешү төзелде.

Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Халыкара кооперацияләр һәм лицензияләү департаменты җитәкчесе Роман Чекушов сүзләренә караганда, «KazanForum»ның төп нәтиҗәләреннән берсе ислам илләре белән уртак проектларны тормышка ашырудан һәм әлеге илләргә товар озатуда сизелерлек алга китүдән гыйбарәт. Үз фикерен дәлилләп тә күрсәтте ул. Мәсәлән, форум кысасында Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә Россия компанияләренең эшен җәелдерүгә бәйле җентекле сөйләшүләр узган. Билгеле булганча, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән Казанга шактый саллы делегация килде.

– Без зур, стратегик әһәмияткә ия булган проектлар турында фикер алышырга әзер, – диде Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең тышкы сәүдә министры Тани бән Әхмәт Әл- Зәйуди форумда Татарстан Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин белән очрашканда. – Ике яклы элемтәләрне җәйлауда Татарстан төп хезмәттәшебез икәнен дә күреп торабыз. Казанга өченче тапкыр киләм. Төбәкнең үсешен, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов башкарган уңай эшләрне күрәм.

Россия Президенты Владимир Путин карары белән быел федераль дәрәҗәдә узган чарада логистика мәсьәләсенә дә зур игътибар бирелде. Көньяк-Көнчыгыш Азия, Якын Көнчыгыш, Африка белән юл мәсьәләсендә элемтәләрне җәйлауның әһәмиятен Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкиле дә билгеләп үтте.

– Мисырда Россия сәнәгать зонасы проектын яңадан эшләтеп җибәрдек. Май азагында ук илнең 40ка якын компаниясе бу илгә эш сәфәренә китәчәк. Алар Сүэеш каналы махсус икътисадый зонасында сәнәгатьне урнаштыру мөмкинлекләрен карап тикшерәчәк, – диде Чекушов.

Форумда катнашкан Мисыр кунагы, гарәп илләренең совет чорындагы һәм Россия вузларын тәмамлаган чыгарылыш студентлары берлеге рәисе Шәриф Хассан Гед әйтүенчә, читтән басым ясауга да карамастан, Россия хезмәттәшләре арасында абруйлы урын алып тора.

– Мисыр әлеге санкцияләрдән баш тарта. Дөнья күләмендә күп кенә илләр дә нәкъ безнеңчә эшләде. Ни кызганыч, Көнбатышта Россияне басым ясап кына дөньяның башка илләреннән өзәргә мөмкин түгел икәнен аңламадылар. Көнчыгышта без моны бик яхшы аңлыйбыз, – дигән ул «Татар-информ» хәбәрчесенә.

Бу хакта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин да әйтте.

– Бер генә мөселман иле дә безгә каршы санкцияләр кертмәде һәм Көнбатыш илләре керткән санкцияләрне хупламады. Димәк, мөселман илләре – безнең ышанычлы хезмәттәшләребез, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

Имтихан тапшыру – укучылар, аларның әти-әниләре өчен һәрвакыт борчылу һәм зур сынау. Шуңа күрә аның нинди шартларда узасына игътибар итүегезне үтенәм. Законның кырыс булуы аңлашыла. Әмма безне юридик факультетта, ул үтәлергә тиеш, дип өйрәттеләр. Рособрнадзорның имтиханнар тапшыруны тикшереп торучы хезмәткәрләре артыгын борчымасын.

(«Эшлекле дүшәмбе»дә сөйләгәннәрдән)

РОССИЯДӘ – ЭШМӘКӘРЛЕК

Россиядә 15 ел эчендә эшмәкәрләр саны 4тән 8 процентка кадәр арткан. Бу хакта Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге хәбәр итә.

ЭШМӘКӘРЛЕККӘ МӨНӘСӘБӘТЕГЕЗ НИНДИ?

- 42% – эшмәкәр булырга теләми
- 27% – үз эшен башларга теләр иде
- 21% – элек мондый теләк бар иде, хәзер юк

Түләргә туры киләчәк

Татарстанның суд приставлары ел башыннан бирле барлыгы 306 миллион сум күләмендә алимент түләтүгә ирешкән. Республиканың Баш суд приставы урынбасары Елена Варфоломеева әйтүенчә, бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 108 миллион сумга күбрәк. Хәзерге вакытта суд приставлары алимент түләтү буенча 20 меңгә якын эшне карый.

Республикада, Халыкара балаларны яклау көненә багышлап, «Суд приставлары – балаларга» акциясе башланды. Ул 1 июньгә кадәр дәвам итә. Акциянең максаты – алимент түләмәүчеләрнең бурычларын түләтү эшен яхшырту һәм җәмәгатьчелек игътибарын балаларның хокукларын саклауга җәлеп итү. Чара кысасында бухгалтерияләрдә бурычны түләтү хисабына акча тотып калу һәм күчерүнең дөреслеген тикшерү күздә тотыла. Моннан тыш «Мобильный розыск» һәм «Дорожный пристав» программалары нигезендә бурычларны эзләү чаралары үткәреләчәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ҮЗГӘРЕШЛӘР ЧОРЫ ЯКЫНЛАШКАНДА

Үткән атнада глобаль сәясәттә тектоник үзгәрешләргә китерергә тиешле өч мөһим вакыйга булды: Япониядәге Хиросимада G7 лидерларының чираттагы очрашуы үтте, Гарәп илләре лигасы зур саммитка җыелды, борынгы Кытай шәһәре Сианьда биш Урта Азия республикасы лидерларының Си Цзиньпин белән очрашуы узды. Очрашуларда Россия катнашмаса да, аларда Россия язмышына кагылышлы мәсьәләләр хәл ителде.

Сүзне Гарәп илләре лигасыннан башлау отышлы булыр кебек. 1945 елда ук төзелгән лига гарәп илләрен һәм гарәп теле рәсми тел булып саналган илләрне берләштерә. Җиддәдә уздырылган быелгы саммитка славян телле дәүләт лидеры, милләте белән гыйбри булган Зеленский килеп төшүе гаҗәп тоелмыймы сезгә? Без «Ватаным Татарстан»да гел искәртеп килдек: Россиягә Көнбатыш илләренең мөселман дөньясы белән коалиция төзүеннән сакланырга кирәк. Зеленскийның Согуд Гарәбстанында узган зур җыелышка килеп, анда чыгыш ясавы, гарәп илләре лидерлары белән күзгә-күз очрашулар да уздыруы – шул без кисәткән коалициянең нигез ташларын салырга омтылыш ул. Саммит нәтиҗәләре буенча үткәрелгән матбугат конференциясендә Согуд Гарәбстанының тышкы эшләр министры Фейсал бән Фәрхан Әл Сауд гарәп илләренең Украина кризисына мөнәсәбәттә «уңай нейтралитет» саклауларын белдерүе – Мәскәү өчен яхшы хәбәр, әлбәттә. Әмма без сәхнә арты сөйләшүләрендә нинди карарлар кабул ителүен белә алмыйбыз. Гарәп илләренең һәм мөселманнар яши торган башка илләрнең хәзерге көндә зур потенциалга ия икәнлекләрен генә әйтә алабыз. Ул илләр, берләшеп, дипломатик басым гына ясаса да, теләсә нинди глобаль көчне үзләре белән исәпләшергә мәҗбүр итә алалар.

Хиросимада үткән «Зур җиделек» очрашуы да бу юлы үз кысасыннан чыгып китте. Саммитка кунак буларак Һиндстан, Австралия, Бразилия, Индонезия, Вьетнам, Көньяк Корея, Кук утраулары белән Комор утраулары союзы лидерлары һәм… Зеленский чакырылган иде. Бу уңайдан «Российская газета»: «За счет этого представители G7 попытались… изменить позицию не присоединившихся к давлению на Россию стран…» – дип язып чыкты. «Зур җиделек» Украинага «күпме кирәк булса шуның кадәр» ярдәм итәргә әзер булуын һәм дүртенче буын F16 хәрби очкычларын бирү турында игълан итте. Кытайны да Мәскәүгә басым ясарга чакырдылар. Вашингтон ашыгыч рәвештә Пекин белән мөнәсәбәтләрне җылытырга тели. Бу Россияне «горур ялгызлык»та калдыру өчен шулай эшләнә. Дөрес, чиннар Вашингтон кубызына биергә җыенмауларын белдерде, әмма АКШ нинди бонуслар вәгъдә итә бит әле.

Си Цзиньпин Сианьда Урта Азия дәүләтләре лидерларын җыйды, Кытай канаты астында хәрби һәм икътисадый союз төзү турында игълан итте. Урта Азиянең төрки дәүләтләре чин кочагына бик шатланып килеп кермәгәндер, бәлки, вәләкин чынбарлык шундый: я АКШ кубызына биисең, я Россиянең кече туганы булып каласың, я Пекин гарантияләренә таянасың. Үзбәкләр, таҗиклар, кыргызлар, казахлар һәм төрекмәннәр кайсын сайлар?

Россиядә

ФАЙДАСЫ БУЛМАЯЧАК

Без инде апрель аенда ук хәбәр иткән идек: федераль хөкүмәт Дәүләт Думасына чит илгә китеп Россия компанияләренә эшләүче белгечләрдән, туган илләренең салым резидентлыгын югалтканнан соң, физик затларның кеременә салымны (НДФЛ) 30 процент итеп түләтү турында канун проекты тапшырды.

Үткән ел махсус хәрби операция фонында, бигрәк тә өлешчә мобилизация башлангач, йөз меңләгән яшь белгеч – читтән торып эшләү мөмкинлеге булган фрилансерлар, чик аша узып, башка илләрдә сыену урыны тапты. Алар закон бозмадылар, чөнки чикләр ябылмаган, чит илләргә чыгу тыелмаган. Әмма Россия сәясәте орбитасында әйләнгән күп кенә сәясәтчеләр мөһаҗирлекне сайлаган белгечләргә тискәре мөнәсәбәт белдерде, «убыр эзләү» сәясәте уздырырга азапланды. Кремльдә релокантларга аек мөнәсәбәт өстенлек алды барыбер. Читтә яшәүчеләргә санкцияләр кертү ихтималлыгы кире кагылды. Мөһаҗирлектә яшәүчеләрне эзәрлекли башлыйсың икән, иң кирәкле кадрлардан колак кагасың.

Федераль хөкүмәт шулай да релокантларга салым ставкасын күтәрү турында канун проекты эшләп карады. Ул Дәүләт Думасында кабул ителергә тиеш тә иде инде. Без ул закон хакында: «Башта бик дәһшәтле күренсә дә, яңа канун либераль булырга охшаган. Иң мөһиме: мөһаҗирләр бернидә дә гаепләнми. Салымыңны түлә дә тыныч йокла», – дип язган идек. 30 процентлык салым ставкасы чит илдә яшәүчеләрнең барысына да кагылмый, кагылганнар да, теләсәләр, аннан бик җиңел качып котылачак иде.

Канун проекты Думага кертелеп теркәлергә дә өлгермәде, без ул хакта язган язманың карасы кибеп җиткәнче үк, хөкүмәт проектны кире чакыртып алды. Күрәсең, югарыдагылар бик либераль эшләнгән законның да файдасы урынына зыяны күбрәк булачагын төшенеп алды. Салым йөген авырайтсаң, әлегә кадәр Россия компанияләренә эшләгән белгечләр, тәртәне борып, башка ил компанияләренә дә күчә ала. Салымнан качуның башка схемалары да җитәрлек. Хөкүмәттә болай да кычытмаган җирне кашуның файдасы юклыгын аңлау өстенлек итә иде. Канун проекты активлыгы чиктән ашкан кайбер сәясәтчеләрнең «пар»ын чыгару өчен генә эшләнде.

Ниһаять, Мәскәүдә бу мәсьәләгә хәлиткеч нокта куйдылар: яңа канун язып маташуга ихтыяҗ юк. Россиядә торып эшлисеңме, чит ил курортларында яшәгән хәлдә Ватан өчен тир түгәсеңме, салым ставкасы үзгәрешсез кала: һәркем 13–15 процент түли. Компанияләр өчен шулай мәшәкатьсезрәк һәм яхшырак. Югары ставка кертелсә дә, бюджетка бик әллә ни акча яумас иде. Финанс министрлыгында моны яхшы аңладылар. Россия резидентлыгын югалтучыларның бер проблемасы кала әле барыбер. Аларга икеләтә салым түләү куркынычы яный. Үзләре яшәгән илләр яңа резидентлардан салым сорарга мөмкин.

ЕРАК АРАНЫ ЯКЫН ИТЕП

Эшлекле сәфәр

«Бер-беребезгә ышанучы күршеләр». Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Кытайга эш сәфәре барышында кабул итүче як ике арадагы элемтәләрне әнә шулай дип бәяләде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия-Кытай бизнес форумының пленар утырышында катнашу өчен, Шанхайга эш сәфәренә китте. Россия делегациясен Ил Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин җитәкли. Әлеге чарага кадәр Рөстәм Миңнеханов Кытайда Шанхай шәһәре мэры Гун Чжэн белән очрашты.

– Без Шанхайга Россия Хөкүмәте Рәисе җитәкчелегендәге рәсми делегация составында Россия-Кытай бизнес форумында катнашу өчен килдек. Россия делегациясенең килүе – Кытай Республикасы Рәисе Си Цзиньпинның Россиягә бик мөһим дәүләт визитыннан соң хөкүмәт дәрәҗәсендәге җавап сәфәре. Бу – безнең илләр арасында моңарчы күрелмәгән мөнәсәбәтләрнең дәлиле, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Шанхайда барлыгы 26 миллион кеше яши. Шәһәр Кытайның әйдәп баручы сәнәгать, транспорт, сәүдә һәм финанс үзәге булып санала. 2022 ел нәтиҗәләре буенча Шанхайның тышкы сәүдә әйләнеше 619,14 миллиард доллар тәшкил иткән. Әңгәмә барышында яклар Татарстан – Кытай хезмәттәшлегенең югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте. Бүген республиканың Кытай провинцияләре белән 7 килешүе бар. Пекинда Татарстанның сәүдә-икътисадый вәкиллеге эшли.

– Без Татарстан һәм Кытай товар әйләнешенең ел саен артуын күрәбез. Узган ел нәтиҗәләре буенча ул 58 процентка үсте һәм 1,6 миллиард доллардан артып китте, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Хезмәттәшлекне үстерү юнәлешләре турында сөйләгәндә, Рәис IT, логистика, сәламәтлек саклау өлкәләрен мисалга китерде. Рөстәм Миңнеханов фәнни җәмәгатьчелек арасындагы бәйләнешләрне үстерергә дә тәкъдим итте.

– Мин сезне һәм делегация вәкилләрен Кытайда сәламләвемә шатмын. Сез күп тапкырлар Шанхайда булдыгыз, шуңа күрә без сезне якын дустыбыз дип саныйбыз, – диде Шанхай мэры Гун Чжен Рөстәм Миңнехановка. – Кытай белән Россияне уртак таулар һәм елгалар берләштерә. Без – бер-беребезгә ышанучы күршеләр. Әлеге хезмәттәшлек кысасында Шанхай белән Татарстан арасында да дустанә мөнәсәбәт урнашты.

Очрашуда шулай ук мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек һәм Казаннан Шанхайга туры рейслар ачу мөмкинлеге турында да фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов Шанхай мэрын Казанда уздыру ниятләнгән зур бизнес-форумга чакырды. Ул эшлекле элемтәләрне киңәйтүгә юнәлдереләчәк.

Хөрмәт һәм теләк

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кичә туган көнен билгеләп үтте.

«Гаять мөһим эштә зур тәҗрибәгә, Татарстан Республикасы хакына зур казанышларга ия кеше Сез. Искиткеч профессионал, барлык кыенлыкларны җиңә алучы, якташларының мәнфәгатьләренә тугрылыклы хезмәт итүче нык сүзле кеше буларак абруй-хөрмәт казандыгыз. Алга таба да республиканың социаль-икътисадый мөмкинлекләрен тормышка ашыруга төрле яклап ярдәм итәчәгегезгә иманым камил», – диелә Федераль Җыенның Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко котлавында.

«Төбәк карарларын закон нигезенә салып, сайлаучылар мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүче кеше буларак, Татарстан Республикасын үстерүгә саллы өлеш кертеп киләсез. Уңышлар, нык сәламәтлек, иң изге теләкләр телим!» – диелә Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володинның котлау телеграммасында.

«Күп еллар буе Татарстан Дәүләт Советының алыштыргысыз Рәисе, «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең төбәк бүлеге Секретаре булып торасыз. Туып-үскән республикабызга һәм илебезгә файдалы булу омтылышыгыз турында сөйли бу. Сезгә, гаять тәҗрибәле дәүләт эшлеклесе һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклесе буларак, бетмәс-төкәнмәс илһам, киң колачлы эшегездә көч-куәт, ниятләгәннәрегезгә ирешүдә уңышлар телим! Аларның, һичшиксез, сөекле Татарстаныбыз һәм халкыбыз иминлегенә бәйле буласына ышанам!» – дигән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең котлавында.

«Туган көнегез уңаеннан нык сәламәтлек, иминлек, җаваплы эшчәнлегегездә зур уңышлар теләргә рөхсәт итегез. Казахстан һәм Россиянең стратегик партнерлыгы кысасында Казахстан белән Татарстан арасындагы дустанә мөнәсәбәтләрнең алга таба үсәчәгенә ышанам», – диелгән Казахстан Парламенты Мәҗлесе Рәисе Ерлан Кошановның котлавында.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исеменә Россия субъектларының дәүләт хакимияте законнар чыгару органнары җитәкчеләре, төбәкләр башлыклары, Дәүләт Думасы депутатлары, чит илләрнең Казандагы дипломатик вәкилләкләре җитәкчеләреннән котлаулар килде.

Фәрит Мөхәммәтшин туган көне уңаеннан җылы котлаулар өчен рәхмәт белдерде. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе үзен котлаучыларның барысына да нык сәламәтлек, иминлек, барлык башлангычларында уңышлар теләде.

Барасы як билгеле

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ислам илләре белән хезмәттәшлекнең тагын бер мөһим юнәлеше – ислам банкингы. Форумда билгеле булганча, алдагы өч елда ислам финанслары күләме 20 миллиард сумга җитәргә мөмкин. Бу хакта журналистларга «Сбербанк» идарәсе рәисенең беренче урынбасары Александр Ведяхин әйтте. Дөрес, бу – әлегә фараз гына. «Әмма ил төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда булган ихтыяҗ әнә шулай фикер йөртергә җирлек бирә», – дип белдерде Александр Видяхин. Ул кредит оешмасының ислам банкингы юнәлешендә канун проекты әзерләүдә катнашуын да әйтте.

– Канунсыз эшләү читен, әлбәттә. Ул без тәкъдим итә торган хезмәтләрне стандартлаштыру өчен кирәк. Алар барысы да шәригать кануннарына туры килә. Киләчәктә башка кредит оешмалары да бу эшкә кушылыр, әлеге юнәлештә көндәшлек барлыкка килер дип ышанам, – диде Александр Ведяхин.

Билгеле булганча, «Сбербанк» Казанда тәүге ислам банкингы бүлекчәсен ачты. Форумда яңалык та җиткерделәр. Ислам банкингы турындагы закон Россия Дәүләт Думасында икенче укылышка әзерләнгән. Бу хакта журналистларга Татарстан Диния нәзарәтенең Галимнәр шурасы әгъзасы Рөстәм хәзрәт Нургалиев хәбәр итте.

Марат Хөснуллин җыен эшенә йомгак та ясады. Бу хакта ул үзенең телеграм-каналында сөйләде.

– Форум бик югары дәрәҗәдә узды. Быел ул тәүге тапкыр федераль статус алды. Моның өчен Россия Президенты Владимир Путинга рәхмәт әйтәсем килә. Чараны оештыруда күп кенә федераль министрлыклар һәм ведомстволар катнашты. Әлбәттә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм аның командасы башкарган эш бәяләп бетергесез, – диде ул.

Ашаган белми, тураган белә, ди. Казан мэры Илсур Метшин «эшлекле дүшәмбе»дә форумны оештыру эшенә катнашы булган һәркемгә рәхмәт әйтте.

– Без зур һәм җаваплы эш башкардык, – диде ул. – Татарстан башкаласына 80нән артык чит илдән 15 меңнән артык кунак килде. Универсиададан соң беръюлы бу кадәр күп кунак кабул иткәнебез юк иде әле. Спортчылар Универсиада авылында гына торса, бу юлы исә форум катнашучылары төрле урыннарда яшәде. Кунаклар Казанны чиста, төзекләндерелгән, ә и мөһиме – кунакчыл һәм киң күңелле шәһәр дип бәяләде.

Аның әйтүенчә, безгә әлеге исемне алга таба да саклап калырга кирәк.

– Җитәкчелек, шул исәптән федераль үзәктән килүчеләр бүген ил күләмендә дә мондый зур чара оештыра алырлык шәһәрләр сирәк булуын билгеләп үтте, – диде мэр.

Сүз уңаеннан, Казанда узган форумны кайберәүләр киләсе елда башкалада үткәреләчәк БРИКС дәүләт башлыклары очрашуына әзерлек дип тә бәяләде. Дөрес, Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина бу ике чараны бутамаска киңәш итте. Ничек кенә булмасын, киләсе елга «KazanForum»ны тагын да зуррак итеп оештырырга вәгъдә иттеләр. Әйткән сүз – аткан ук.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТАТАРЛЫК ТЕРӘГЕ

Узган атнада бер меңнән артык имам «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы кысасында көнүзәк мәсьәләләр турында сөйләште. Атна азагында исә, Болгар җиренә барып, илгә-көнгә тынычлык сорап дога кылды.

Таянычыбыз – имамнар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов форумга җыелган дин әһелләренә рәхмәтен җиткерде.

– Киләчәгебезне тәрбияләүдә, гореф-гадәтләрне сеңдерүдә татар дин әһелләренә зур ышаныч баглыйбыз. Әлбәттә, без сезгә таянабыз. Сез – ышанычыбыз, – диде Рәис. – Рәхмәтне сез безгә түгел, без сезгә әйтергә тиеш. Һәммәгезнең үз эше бар, ә дин юлын үзегезгә өстәмә хезмәт итеп аласыз.

Рәхмәтләргә бай чыгышында республика җитәкчесе Россия вице-премьеры Марат Хөснуллинны аерым телгә алды. Милләттәшебез дә, Мәскәүгә безнең тавышны ишеттерүче дә ул бит.

– Ул барлык мәсьәләләрдә булышырга тырыша. Марат Шакирҗан улына бу эшне Президентыбыз, Премьер-министр йөкләде. Шундый егетләребез булганда, без күп эшләр башкара алабыз! – диде Рәис.

Милли һәм динле

Форумның утырышында «берләшү» һәм «ярдәмләшү» сүзләре еш яңгырады. Исегездә булса, Курган өлкәсендәге Йолдыз (Эчкен) татар авылында коточкыч янгын чыгып, зур зыян китерде. Авылны яшәтәсе иде. Форумда катнашучылар Йолдызны яшәтүне татарларның бердәмлеген һәм берләшүен дәлилләгән символ итеп күрергә тели.

– Халкыбызны бәйрәм көннәре, Сабан туйлары гына берләштерми. Аллаһы Тәгалә тарафыннан сынау итеп җибәрелгән афәтләр, кайгылар да бердәмлегебезне ныгыта, – диде бу җәһәттән Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев.

Аның әйтүенчә, татар авылын торгызуда бөтен кешеләр, татар эшмәкәрләре катнаша. Әйтик, «Татнефть» компаниясе тиз сафка баса торган йортлар салуда булышачагын белдергән. Җитәкче үзе дә шушы көннәрдә Йолдыздагы милләттәшләребез белән күрешергә исәпли. «Шул рәвешле Йолдыз авылы татар халкының бердәмлеге символына әверелергә мөмкин», – диде Милли Шура рәисе.

Йолдыз әле дә ярдәм өмет итә. Пленар утырышта бу хакта каза күргән авылның имамы Әхмәдулла хәзрәт Хәбибуллин да әйтте. Алар өчен ярдәмнең артыгы юк әле.

Россия мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин дә Кургандагы татар авылына булышуны бердәмлек үрнәге дип атады. Игелек кылудан туктамаска да өндәде.

Моннан тыш, Равил хәзрәт Татарстанның Россия күләмендә мөһим миссия башкаруын әйтте. Бигрәк тә бу эшнең республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов җилкәсенә төшүенә басым ясады. Җаваплы, әмма татарларга хас эш ул.

– Татарстанга илебез җитәкчелеге Россия белән ислам дөньясы арасында күпер булдыру бурычын йөкләде. Бу – гасырлар дәвамында татарга хас булган миссия! Татарга тылмач кирәкми, дигәннәре моны раслый, – диде ул.

Алга таба форум кысасында «авырткан» урыннарга тукталдылар.

Әйтик, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җыелып сөйләшү өчен күркәм дә, күңелсез дә вакыйгаларның күп булуын искәртте. Мисал итеп, ул Кургандагы янып беткән Йолдыз авылын китерде, шулай ук «Сахих әл Бохари»ның бер тәрҗемәсе тыелуны атады. Соңгысы уңай хәл ителсә дә, мөфти, шуңа охшаш хәлгә янәдән төшмәс өчен, уяу булырга кирәклеген искәртте.

– Проблеманың нигезендә судларның гаделсез карарлары түгел, ә мөселман китапларына дини-фәнни анализ урынына психологик-лингвистик анализ ясалу ята. Китапларның эчтәлеген экстремистик дип шуның нигезендә таныйлар. Ягъни Россиядә дини әдәбиятка экспертизаны тиешле әзерлеге булмаган белгечләр ясый. Югыйсә басылып чыкканчыга кадәр, китап экспертиза үтсә, күп сораулар хәл ителер иде, – диде мөфти.

Камил хәзрәт Сәмигуллинның әлеге мәсьәләгә карата тәкъдимнәре дә бар. Беренчесе – татар дин әһелләренә дини хезмәтләрне татар телендә язу һәм бастыру. Тагын бер тәкъдим – ил күләмендә дини белгечләр оешмасын булдыру. Шул ук вакытта алар көн кадагындагы сорауларны да уртак көч белән чишәр иде. «Алар күп: мәктәп һәм бакчаларда хәләл туклану, мәчет-мәдрәсәләрнең җитмәве, хиҗабны тыю…» – диде Камил хәзрәт.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Милләт һәм милли үзенчәлегебез өчен борчылып чыгыш ясаучылар да булды. Дини һәм милли үзенчәлегебез, Аллаһ йортларына имамнар җитмәү турында Россия мөселманнары Дини Мәҗлесе рәисе, Мәскәү шәһәре, Үзәк төбәк һәм Чувашия Республикасы мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов әйтте.

– Шөкер, дини уку йортларының күбесе Татарстанда урнашкан. Ләкин, кызганыч, дини югары уку йортларын тәмамлаган яшь татар белгечләребез Россиянең ерак төбәкләренә китәргә теләми. Күп мәчетләрдә имамнар җитми. Яшь дин әһелләрен тәэмин итү мәсьәләсе бик күптәннән хәл ителми. Шул ук вакытта, Урта Азия һәм Кавказ якларында тәрбияләнеп белем алган яшь белгечләр, безнең якташларыбыздан аермалы буларак, социаль пакетсыз да эшләргә әзер, – диде Әлбир Крганов.

Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нәфигулла хәзрәт Аширов киләчәк турында уйланырга чакырды. Ягъни дини мирас киләчәккә барып җитәрме? Кем кулына тапшырасы?

– Ата-бабаларыбыз безнең алга Казан басмасын куйган кебек, без балаларыбызга нәрсә калдырабыз? Өстебездәге чапан-чалмаларны калдырабызмы? Яки шул Коръәннең мәгънәсен күңелләренә сеңдереп, калеб-йөрәкләренә кертеп, аларны да балаларын шул юлда тәрбияләргә өйрәтәбезме? – дип сораулар яңгыратты дин әһеле мөнбәрдән.

Ата-бабалар җирендә

Диннән башка киләчәкнең юклыгын Изге Болгар җыенында да әйттеләр. Сүз уңаеннан, быелгы чарага 20 меңнән артык кеше килгән иде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Болгар җире – нигезебез ул.

– Ел саен язын шушында җыелабыз. Болгар – безнең нигезебез ул. Болгар булганда, динебез дә, телебез дә, гореф-гадәтләребез дә яшәр, – диде ул. – Шушы көннәрдә Патриарх Кирилл да Казанга эш сәфәре белән килде. Ул бик мөһим сүзләр әйтте: ислам һәм православие дөньяда барган ялгыш процессларга карата каршы тора ала. Бу чыннан да шулай.

Җыен кунагы – Россия Президентының Эчке сәясәт идарәсе дини оешмалар белән хезмәттәшлек департаменты башлыгы Евгений Еремин да Болгар җиренең кадерле мирас булуын ассызыклады.

– Болгар – күпмилләтле һәм күпдинле Россия халкының изге урыннарының берсе. Россиядә яшәүчеләрнең уртак рухи кыйммәтләре, бердәмлеге бар, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«ИНФОРМАЦИЯ, РАСКРЫВАЕМАЯ АО «ТАТЭНЕРГО», В СООТВЕТСТВИИ СО СТАНДАРТАМИ РАСКРЫТИЯ ИНФОРМАЦИИ ОПТОВОГО И РОЗНИЧНЫХ РЫНКОВ ЭЛЕКТРОЭНЕРГИИ, УТВЕРЖДЕННЫМИ ПОСТАНОВЛЕНИЕМ ПРАВИТЕЛЬСТВА РФ ОТ 21.01.2004 № 24»

1) Годовая бухгалтерская отчетность АО «Татэнерго» за 2022 год, а также аудиторское заключение размещены в сети Интернет на сайте раскрытия информации ООО «Интерфакс-ЦРКИ»
http://www.e-disclosure.ru/portal/files.aspx?id=772&type=12
https://www.tatenergo.ru/about/soobshcheniya-raskrytii-informatsii/raskrytie-informatsii-uchastnika-ore/

2) Информация о тарифах на поставку электрической энергии с указанием решения уполномоченного органа исполнительной власти субъекта Российской Федерации об установлении тарифов и источника официального опубликования такого решения

Тарифы на поставку электрической энергии (мощности) АО «Татэнерго» на 2023 год

Наименование документа об установлении тарифов	Приказ ФАС от 12.12.2022 № 969/22	
Источник официального опубликования решения	Официальный интернет-портал правовой информации http://pravo.gov.ru, 21.12.2022	
Станция	**Тарифная ставка на электричекую энергию, руб./МВт. ч (без НДС)**	**Тарифная ставка на мощность, руб./МВт в мес. (без НДС)**
2023 год		
Казанская ТЭЦ-1 без ДПМ/НВ	1 314,56	103 825,06
Казанская ТЭЦ-1, объект N 6 (ПГУ) ДПМ НВ	1 086,40	х
Казанская ТЭЦ-1, объект N 7 (ПГУ) ДПМ НВ	1 067,43	х
Казанская ТЭЦ-2 без ДПМ/НВ	1 335,69	109 975,27
Казанская ТЭЦ-2 ПГУ (БЛ 1, 2) ДПМ НВ	985,90	х
Заинская ГРЭС (блок 2,3,4,7-10)	1582,36	107 206,99
Набережночелнинская ТЭЦ	1 328,48	128 763,20
Нижнекамская ГЭС	39,20	128 986,48

3) Структура и объём затрат на производство и реализацию товаров (работ, услуг)

Фактическая структура производственной себестоимости (с учётом покупной электроэнергии и мощности на ОРЭМ) АО «Татэнерго» за 2022 год

№ п/п	Наименование затрат	% от общей суммы расходов
1	2	3
1.	Топливо	50
2.	Энергия	6
3.	Вспомогательные материалы	1
4.	Услуги производственного характера	2
5.	Оплата труда и страховые взносы	13
6.	Амортизация	9
7.	Расходы на ремонт основных средств	6
8.	Прочие расходы	9
9.	Расходы на покупку электроэнергии (мощности)	4

Расходы на производство и реализацию производимой продукции (с учетом расходов на покупку электроэнергии мощности на ОРЭМ) по АО «Татэнерго» за 2022 год составили 41 482 990 руб.

4) Информация о выбросах загрязняющих веществ, оказывающих негативное влияние на окружающую среду за 2022 год, и мероприятиях по их сокращению на 2023 год:

№ п/п	Экологические показатели	Единица измерения-тонны	2022	2023	
			Факт по итогам года	Наименование мероприятия по сокращению выбросов загрязняющих веществ	План/цель
1	2	3	4	5	6
1	Объем выбросов загрязняющих веществ в атмосферу:				
	1.1 оксид азота	т/год	7525,14	**Заинская ГРЭС.** Промывка поверхностей нагрева регенеративных воздухоподогревателей, энергетических паровых калориферов котлов №№ 2-12 **Набережночелнинская ТЭЦ.** – Чистка трубок ПСГ-1,2 турбин ст. № 3-8,10,11. – Чистка конденсаторов ТГ ст. № № 1-8,10,11.	Снижение объёма выброса NOx на 13,97 т
	1.2 диоксид серы	т/год	983,782		Снижение выбросов SO2 на 15,84 т
	1.3 твердые вещества	т/год	20,792		Снижение выбросов сажи на 0,335 т, маз.золы на 0,043 т
	1.4 летучие органические вещества	т/год	68,719		
	1.5 оксид углерода	т/год	1759,434		Снижение выбросов CO на 2,49 т
	1.6 углеводороды (без летучих органических соединений)	т/год	411,955		
	ИТОГО:		**10772,534***		
*с учетом прочих газообразных и жидких веществ 2,712 т					

5) Информация о режиме использования и состоянии водных ресурсов:

Основные показатели режимов работы Нижнекамского водохранилища за период с 01.01.2022 по 31.12.2022

№ п/п	Наименование гидроэлектростанции (далее – ГЭС)/ рынок, на котором гидроэлектростанция осуществляет деятельность (оптовый рынок или розничные рынки)	Пропускная способность водосбросных сооружений при наивысшем проектном подпорном уровне (далее – НПУ) верхнего бьефа, который может поддерживаться в нормальных условиях эксплуатации гидротехнических сооружений (единица измерения – м/сек)	Выработка электроэнергии за отчетный период (единица измерения – тыс. кВт/ч)	Уровни водохранилищ по состоянию на отчетную дату (измеряется в метрах)		Тип, мощность генератора
				НПУ	Минимальный уровень, допустимы в условиях нормальной эксплуатации водохранилища (сокращенное название – УМО)	
1	2	3	4	5	6	7
1	Нижнекакмская ГЭС	31650	1794685,749	63,3	62,7	СВ-1470/149-104У4, 91800/78000 кВа/кВт

6) Информация об инвестиционной программе:

Раскрытие информации об инвестиционных программах производителей электрической энергии

АО «Татэнерго», ул. Марселя Салимжанова, д. 1, г. Казань, Республика Татарстан, 420107
(Наименование организации с указанием местонахождения и реквизитов)

Наименование инвестиционной программы, сроки начала и окончания реализации инвестиционной программы	Дата утверждения инвестиционной программы	Цели инвестиционной программы	Наименование органа исполнительной власти, утвердившего инвестиционную программу	Информация об использовании инвестиционных средств за отчетный период		
				Наименование мероприятия	Сведения об использовании инвестиционных средств за отчетный год (тыс. руб.)	Источник финансирования инвестиционной программы
1	2	3	4	5	6	7

Примечание:
Деятельность по оказанию услуг по передаче электрической энергии, осуществляется в условиях естественной монополии и регулируется в соответствии с законодательством о естественных монополиях, Федеральным законом «Об электроэнергетике» и иными федеральными законами. АО «Татэнерго» в области электроэнергетики не является субъектом естественной монополии и не подпадает под критерии отнесения субъектов электроэнергетики к числу субъектов, инвестиционные программы которых утверждаются и контролируются уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, органами исполнительной власти субъектов Российской Федерации (ст. 21 35-ФЗ «Об электроэнергетике).
Формирование Инвестиционной программы по электроэнергии не требуется.
Инвестиционная программа АО «Татэнерго» формируется в соответствии с требованиями постановления от 5 мая 2014 г. N 410 «О порядке согласования и утверждения инвестиционных программ организаций, осуществляющих регулируемые виды деятельности в сфере теплоснабжения, а также требований к составу и содержанию таких программ».

7) Информация о расходах электроэнергии на собственные и хозяйственные нужды генерирующего оборудования АО «Татэнерго» при выработке электрической и тепловой энергии (раздельно) с указанием наименования и типа станции за 2022 год.

Информация о расходах электроэнергии на собственные и хозяйственные нужды генерирующего оборудования АО «Татэнерго» при выработке электрической и тепловой энергии (раздельно) с указанием наименования и типа станции за 2022 год

№ п/п	Наименование, реквизиты, тип электростанции	Расход электроэнергии (единица измерения – тыс. кВт/ч)		
		на собственные нужды		на хозяйственные нужды
		на выработку электрической энергии	на выработку тепловой энергии	
1	2	3	4	5
1	Казанская ТЭЦ-1	96 667,906	36 021,479	631,414
2	Казанская ТЭЦ-2	94 212,834	56 785,082	1 292,883
3	Заинская ГРЭС	294 316,197	9 223,378	2 910,760
4	Набережночелнинская ТЭЦ	179 316,944	125 335,898	870,530
5	Нижекамская ГЭС	23 485,925		1 152,202
		всего: 687 999,806	всего: 227 365,837	всего: 6 857,789

8) Информация об используемом топливе на электрических станциях с указанием поставщиков и характеристик топлива:

Наименование электростанции	Вид используемого топлива	Удельный расход условного топлива на отпуск электроэнергии с шин, г/кВт/ч *	Характеристика топлива (теплотворная способность, ккал/м³, ккал/кг)	Общий расход топлива электростанции за отчетный период, тыс. м³, тонн	Информация о поставщике топлива (наименование, место нахождения)
1	2	3	4	5	6
Казанская ТЭЦ-1	Газ	226,9	8303	531 305	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9388	164	ООО «КАРАТ», г. Казань
РК «Горки» (КТЭЦ-1)	Газ		8292	60 821	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
РК «Азино» (КТЭЦ-1)	Газ		8274	112 048	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
Казанская ТЭЦ-2	Газ	216,5	8303	575 024	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9006	4	ООО «ППТК», г. Казань
	Уголь		6300	68	ООО «РуТЭК», г. Самара
РК «Савиново» (КТЭЦ-2)	Газ		8276	103 434	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
Заинская ГРЭС	Газ	377,4	8071	1 249 812	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9487	3 472	ООО «КАРАТ» г. Казань; АО «ТАИФ-НК» г. Нижнекамск
Набережночелнинская ТЭЦ	Газ	302,8	8222	1 294 796	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9587	14 552	ООО «КАРАТ» г. Казань; АО «ТАИФ-НК» г. Нижнекамск
Тепловая станция ЮЗЧ (КЦ БСИ НЧТЭЦ)	Газ		8213	6440	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9566	6	ООО «КАРАТ», г. Казань

* – в соответствии с РД 34.08.552-95 расчет удельного расхода условного топлива на отпуск электроэнергии с шин электростанции по каждому виду топлива не ведется. Информация предоставлена в соответствии с формой 6-ТП за 2022 год

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы Ветераннар советы рәисе, «Татарстан Республикасының ишкәкле спорт федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы вице-президенты **Плюшкин** Александр Васильевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

2022/2023 еллар сезоны ВТБ Бердәм лигасы чемпионатында һәм баскетбол буенча Россия чемпионатында җиңү яулаулары өчен Казан шәһәренең «Уникс баскетбол клубы» җирле иҗтимагый оешмасы уенчылары: команда капитаны, форвард **Воронцевич** Андрей Константинович, сакчы **Димитриевич** Ненад, сакчы **Жбанов** Георгий Игоревич, сакчы **Зайцев** Вячеслав Андреевич, форвард **Лабери** Луин, сакчы **Макон** Дэрил, сакчы **Найт** Марко Шайдеррик, үзәктәге уенчы **Рейнольдс** Джален Диор, форвард **Хантер** Винсент Шамар; 2022/2023 еллар сезоны ВТБ Бердәм лигасы чемпионатында һәм баскетбол буенча Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен Казан шәһәренең «Уникс баскетбол клубы» җирле иҗтимагый оешмасы хезмәткәрләре: баш табиб **Багданов** Искәндәр Ильяс улы, тренер **Бигиев** Артур Вахит улы, баш тренер **Перасович** Велимир «**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Уникс баскетбол клубы» җирле иҗтимагый оешмасы хезмәткәрләре: халыкара бүлек башлыгы **Алимова** Эльвира Абдулкәбир кызына, вице-президент **Әхсәнова** Ольга Евгеньевнага, команда өлкән администраторы **Трошкин** Александр Александровичка, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Юность» спорт комплексы» муниципаль бюджет учреждениесенең спорт буенча әйдәүче белгече **Әхмәтҗанов** Марат Мөхәммәтхан улына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Юбилейный» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Купкенов** Минсәит Минтаһир улына, «Татарстан Республикасының самбо федерациясе» төбәк физкультура-спорт иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Мәдьяров** Рафикъ Әхмәди улына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Мөхәммәдиев** Әүхәт Хәлим улына, «Стрела» регби клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш тренеры **Нел** Джейкобус Полуска, «Регби буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе тренеры **Петрушинин** Игорь Александровичка, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең футбол буенча тренеры **Праслов** Сергей Александровичка, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең физик культура һәм спорт кафедрасы доценты **Титова** Елена Борисовнага, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «САБА-АРЕНА» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең фехтование буенча тренеры **Шаһиева** Эльвира Хәниф кызына «**Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белеп тору зыян итмәс

Акчасыз гына бакчалы булу

Бакчачыларга һава торышы бик җайлы туры килде быел. Әмма матурлыкка хозурланып, рәсмиләштерү эшләрен дә онытып җибәрергә ярамый. Хәзер бит яңалыклар да артып кына тора. Бакча өйләрендә җәен генә түгел, ел әйләнә, торак йорт буларак та яшәргә мөмкин. Кагыйдәләрне белеп кенә бетер. Татарстан Росреестры белән элемтәгә кереп, без дә бакчачыларга ярдәмгә килергә булдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

1 Күчемсез милекне (торак йортлар, бакча өйләре, шәхси гаражлар, мунчалар һәм башка шундый корылмаларны) гадиләштерелгән ысул, ягъни «дача амнистиясе» буенча рәсмиләштерү өчен, рөхсәт итүче бернинди документлар да таләп ителми.

2 Капиталь төзелеш объектларын (мәсәлән, торак һәм бакча йортларын) рәсмиләштергәндә, «дача амнистиясе» 2031 елның 1 мартына кадәр дәвам итә. Җир участокларына хокукларны теркәү (бу шәхси торак, бакча йортлары, гараж төзелеше өчен файдаланылган җирләргә карый) өчен «дача амнистиясе»нең срогы каралмаган.

3 «Дача амнистиясе» бакчачылык ширкәте, шәхси торак, гараж төзелешләре һәм ярдәмче хуҗалык эшләре алып бару (торак пунктлар чикләрендә) өчен бүленеп биргән җирләргә карый.

4 Торак һәм бакча йортлары шәхси торак төзелеше параметрларына туры килергә, ягъни биеклеге – 20 метрдан, өч каттан артык булмаска тиеш. Моннан тыш объектның урнашуы, чикләре билгеләнгән кагыйдәләргә туры килеп тору шарт.

5 Әгәр дә җир участогында (хәтта бакчачылык ширкәтендә дә) шәһәр төзелеше регламентлары буенча йорт төзү каралмаган булса, бу мәйданда төзелеш эшләре алып барырга рөхсәт ителми.

6 Торак яки бакча йорты төзелешен башлаганчы, җир участогының нинди территориаль зонада урнашканын һәм нинди чикләүләр кертелгәнен ачыкларга кирәк. Моның өчен җирле үзидарә органына (Казан шәһәрендә ул – Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе) мөрәҗәгать итегез һәм Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең мәгълүмат системасыннан өземтә таләп итегез. Шулай ук Бердәм дәүләт күчемсез милек регистрыннан (ЕГРН) өземтә кирәк. Анда бу территориядән файдалану буенча бөтен шартлар да күрсәтеләчәк.

7 2031 елның 1 мартына кадәр бакча участокларын бушлай хосусыйлаштырырга мөмкин. Моңа беренче чиратта 2019 елның 1 гыйнварына кадәр ширкәттә әгъза булып торучылар хокуклы. Тик шартлары да бар. Җир участогы дәүләтнеке булып, гражданның кулында ширкәт әгъзасы дигән документ булган очракта гына хосусыйлаштыру турында сүз алып барырга мөмкин.

8 Әгәр җиргә дә, торак йортка да бернинди документлар юк икән, «дача амнистиясе»нең 2 пунктыннан файдаланырга мөмкин. Бу очракта хокук бирүче документлар әзерләү өчен җир участогы урнашкан район хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

9 Бакча йортын торак йорт дип танысыннар өчен, күчемсез милек урнашкан җирлекнең башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә, гариза язарга, объектның техник халәтен бәяләүче документ тапшырырга кирәк.

10 «Дача амнистиясе» буенча күчемсез милекне теркәү һәм бушлай хосусыйлаштыру 5 көн эчендә башкарыла. Документларны электрон рәвештә биргәндә, 3 көн дә җитә. Дәүләт пошлинасының күләме – 350 сум.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Белдерү

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.: +79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, МО «г. Казань», г. Казань, Авиастроительный район, ул. Маршала Говорова, д. 34а, с кадастровым номером 16:50:221036:1.

Заказчиком кадастровых работ является Гиззатуллин Ильнур Фаритович (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11. Тел.: +79272414666).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 30 июня 2023 г. в 10.00 г.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 29 мая 2023 г. по 29 июня 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 29 мая 2023 г. по 29 июня 2023 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:221036:3 (Республика Татарстан, МО «г. Казань», г. Казань, Авиастроительный район, ул. Маршала Говорова, д. 34).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Безнең Салават

Күңелгә кереп калган, әледән-әле искә төшереп, йә елмаерга, йә сискәнергә мәҗбүр итә торган хатирәләр – гомер юлыбызның онытылмас бер мизгеле ул. Ә бит, бер уйласаң, тормышның мәгънәсе дә шул мизгелләрдән гыйбарәт. Тормыш – сәхнә, дибез. Һәм ул сәхнәдә һәркайсыбызның – үз урыны, үз роле. Әйе, үз роле. Кем аны ничек башкара – монысы инде талантыңа гына түгел, табигатеңә, холкыңа, ягъни кешелек сыйфатларына карый. Әнә шулар булганда гына чын мәгънәсендә халык мәхәббәтен яулап була.

«Сәхнә» дигән серле дөньяны гаҗәеп моңлы тавышы, мөлаемлыгы, сөйкемлелеге, гадилеге белән үзенә караткан Салават Фәтхетдинов турында сүземне уратып башлавымның сәбәбен, аны җырчы гына түгел, шәхес буларак белгән кешеләр аңлый булыр. Концертлар белән беренче мәртәбә ул Кукмарага, ялгышмасам, 1980 ел урталарында килде. Без аның концертын, төгәлрәге, Салават Фәтхетдинов алып барган тамашаны Әсән-Елга авылындагы мәдәният сараенда карадык. Хатыны Ләйсән бик матур итеп җырлады. Ә ул бик оста итеп сөйләде. Әйе, сөйләде, җырламады. Ул чагында әле без аны җырчы буларак белми дә идек. Конферансье залны бер сулышта тотты.

«Әстерханның чикләвеген ватып булмый теш белән,
Сирәк-мирәк урлашмасаң, баеп булмый көч белән», –

дип, тамашачыны туйганчы бер көлдереп тә алды. Ул концерт аннары Кукмара мәдәният сараенда да гөрләп узды. Зал шыгрым тулы иде. Халык беренче күрүдә үк үз итте, яратты. Кукмара халкы аны «безнең Салават» дип йөртә башлады. Бәлкем, Башкортстан егетенең олы сәхнәгә, күренекле шәхес, илдә танылган җырчы булуга тынгысыз сукмагы безнең төбәктән башланганга шулай дип әйтүләре булгандыр. Зирәк бит безнең халык, белеп әйтә ул. Салаватның үзеннән дә: «Татарстанга мин Кукмара аша кердем», – дип әйтүен күп тапкырлар ишеткәнем булды.

1990 нчы елларда республика референдумы булып узды. Шунда без авыл советы сәркатипләрен Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрына концертка алып бардык. Сәхнәгә күз явын алырдай ак күлмәктән Салават Фәтхетдинов килеп чыкты. Аның йөрәкләрне айкап алырдай моңлы тавышы соңыннан бик озак колак төбендә яңгырап торды.

Бүген Салават Фәтхетдинов – Россиянең атказанган, Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты. Аның исеме Казанның Бауман урамындагы «Йолдызлар аллеясы»на кертелгән. Ул – Россия Балалар фондының Татарстан бүлекчәсе директоры, «Салават» эстрада театрының иҗат җитәкчесе. Барына өлгерә. Аның автоспорт буенча халыкара класслы спорт мастеры булуын да онытмыйк.

Быел Салаватыбызның зур сәхнәләрдә чыгыш ясый башлавына – 35 ел! Концертларында еш булам. Әлфия апа исән чагында, аны ничек итеп сәхнәдә җитәкләп йөртүләренә кадәр күз алдында. Кешелекле, миһербанлы булу игътибар үзәгендә булган шәхесләр өчен аеруча мөһим, дип тикмәгә әйтмәдем. Бу шулай. Шуңа да безнең Салават ич ул!

Равия КӘРИМУЛЛИНА,
Кукмара муниципаль районы башлыгы киңәшчесе

СӘЙДӘШ АБЫЙ

Безнең Чапшар, Кили, Пүскән, Нормабаш авылларыннан чыккан танылган шәхесләр арасында Сәйдәш абый Исрафилов – һичшиксез, иң билгелесе һәм иң күренеклесе. Чапшар сигезьеллык мәктәбендә мин укыган елларда ук диварда аның фоторәсеме тора иде.

Мин аңа сокланып карап тора идем. Горур йөз, бөркетнекедәй әллә каян күрә торган күзләр, Кавказ кешеләренекенә охшаган матур, килешле борын. Үткән саен бу фоторәсем мине үзе эзләп таба кебек иде. Әйтерсең миңа Гражданнар сугышы геройлары Григорий Котовский, Василий Чапаев үзләре карап тора. Сәйдәш абыйның йөзе, күз карашы аларныкыннан бер дә ким түгел иде. Мин шул вакытта ук безнең яклардан да нинди күренекле шәхес үсеп чыкканын сизә, аңлый идем.

1972 елда мин, 15 яшьлек малай, Чапшар сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, Казанга укырга чыгып киттем дә тагын өч елдан туган авылым Чапшарга кире әйләнеп кайттым. Рәхмәт яугыры, бәхеткә, әти Тимирязев исемендәге колхозның партком секретаре Рәфкат абый Нигъмәтуллин белән сөйләште дә, шуннан соң мине кохозга рәссам итеп эшкә алдылар. Ул елларда колхозларга кирәк чагында рәссамнарны Казаннан чакырталар иде.

Мин алтынчы класста укыганда Чапшар клубына да Казаннан зур рәссамнар килде, алар Тимирязев исемендәге колхозга рәсем-плакатлар ясадылар. Ат рәсеме ясатып карап, мине дә Казанга рәссамлыкка укырга чакырдылар. Бу рәссамнар икәү иде. Берсе, пеләш башлысы – Исаков Валерий Викторович, ә икенчесе сакалмыеклы иде. Валерий Викторовичның академик, галим Тимирязевны ясаган портреты колхоз рәисенең кабинетын әле хәзерге көннәргә кадәр бизәп торды диярлек. Соңыннан мин бу рәссамнар белән дуслашып китеп, Казанда өйләренә дә барып йөрдем әле.

Шулай итеп, мине колхозга рәссам итеп алдылар. Мин эшли башлаган 1975 елда Сәйдәш абыйны Тимирязев исемендәге колхозның председателе итеп сайладылар. Ул аңарчы колхозның баш инженеры булып эшли иде. Ул вакытларда ук «Сәйдәш әйтте!», «Сәйдәш үзе киләчәк!» – дип кенә сөйләшәләр иде кайбер кешеләр. Кырыйдан карап торсаң, Сәйдәш абый булмаса, колхозның бер эше дә алга бармый кебек тоелды.

Мин үзем аның күзенә чалынмаскарак тырыштым. Чыннан да, ир-ат кеше йә механизатор, шофер, агроном, терлекче булып эшләргә тиеш бит, ә мин ручка, карандаш тотып эшләгән кыяфәттә йөрим. Моны кем аңлап бетерсен инде. Колхозның партком секретаре Рәфкат абый Нигъмәтуллин кул астында эшләдем. Бик киң белемле кеше, икътисадчы, спортчы, белмәгән нәрсәсе юк, тәртипне бик ярата. Бик яратып, Чапшар, Кили, Пүскән, Нормабаш авыллары клубларына төсле, майлы буяулар белән декорацияләр ясадым. Норма клубын, фермасын, Кариле фермасын да рәсем-плакатлар белән бизәдем.

Сәйдәш абый эшләгән еллар бик нәтиҗәле еллар иде. Сәйдәш абый үзен чын шәхес итеп күрсәтте, бөтен талантын, көчен туган якны үстерүгә, күтәрүгә багышлады.

Сәйдәш абый – мәчетләр төзелешенә дә зур көч керткән кеше. Туган авылы Пүскәндә 1995 елның 26 мартында яңа гына төзелгән мәчет ишекләрен ачты. Мәчет авыл халкының тырышлыгы, Тимирязев исемендәге күмәк хуҗалык хисабына төзелә. Хуҗалык җитәкчесе Сәйдәш Исрафиловка авыл халкының рәхмәте чиксез. Бүгенгә кадәр хуҗалык мәчетнең барлык чыгымнарын үз хисабына түләп килә: әтисенә алмашка килгән яшь җитәкче Булат Исрафилов та бу игелекле гамәлне дәвам иттерә.

Мәчет төзелешенә ярдәм итеп, урман кисеп, бурасын бурап, чутлатып, аны күтәрүнең бөтен мәшәкатьләрен һәм чыгымнарын Тимирязев исемендәге күмәк хуҗалык өстенә алган, үзеннән зур өлеш керткән Сәйдәш Исрафиловка, түбәсен калай белән яптырган Фәрит Гыйрфановка Нормабаш халкы да бик рәхмәтле!

Чапшар авылында балалар аз булу сәбәпле, 1977 елда сигезьеллык мәктәп ябылгач, Тимирязев исемендәге хуҗалык, аның җитәкчесе Сәйдәш Исрафилов Чапшарда мәктәп-бакча комплексын төзи. Мәктәп директоры Мулланур Әсәдуллинга, авылдашларга, читтән ярдәм кулы сузучы кешеләргә дә бик нык булышырга, тырышырга туры килә монда.

Шулай ук Чапшар, Кили, Норма авылларындагы мәчетләр төзелешенә дә Сәйдәш абый үз өлешен керткән. Тирә-як авылларга да Сәйдәш абый ярдәм кулы сузды. Их, Сәйдәш абыйга багышлап, үзе эшләгән еллар истәлеге итеп китап нәшер итәргә иде. Бу инде аның үзенә игелек күрсәтү булыр иде.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

Яшьлек хатирәләре

ИСТӘ КАЛУ

Шифаханәдә саунадан соң очраштык та:
– Сез кайдан? – дип сүз каттым берәүгә.
– Үчәлледән. Рөстәмнәрне беләсезме?
– Әйе, туганыбыз, мин – Әсгать абый.
– Мин Марсель булам.

Шул мизгелдә киендем дә, түш кесәмдәге бүлмәм ачкычын карасам, юк дип борчуга төштем. Моны Марсель дә күрде. Куйган киемнәр урынын бөртекләп карагач та, ачкычым күренмәде. Бүлмәмә ашыктым, әллә шунда биктә калдырганмынмы? Кинәт куанычлы аваз:
– Әсгать абый, менә-ә ачкы-ыч!
– Әйе, нәкъ 9 нчы бүлмәнеке!

Марсельгә рәхмәт әйтеп, бүлмәмне ачып кереп утырдым да, менә яңа гына танышымның озакка истә калуы шушы рәвешле буладыр, дип уйга калдым. Әйе, Марсельнең ачкычымны табып, тиз генә күңелемне тынычландыруын һич онытмамдыр. Фәлән-фәлән кеше шундый-шундый игелек кылган, коткарып калган дигән шатлыклы хисләрнең бер мизгелдә тууы да Марсельнең билгесез кешегә ачкычын табып бирүе кебегрәк истә калу буладыр инде! Рәхмәт аңа!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай

«БЕРӘЗГӘЛӘМИЧӘ ЭЧ»

Күңелнең бер почмагында яшеренеп яткан истәлек әледән-әле баш калкыта. Ашлама бушатырга йөргән авыл абзыйларына бәйле ул. Вагоннан ашлама бушатырга автобус белән баралар, арып-талып, автобус белән кайталар. Автобус колхозныкы, йөртүчесе – минем бабай. Көннекен-көнгә азмы-күпме акча да биреп торалар. Хатын-кызлар булса, шул акчага балаларга тәм-том алырга дип, кибет ягына юнәлерләр иде, ир-атлар исә, тамак төбенә җыелган ашлама тузанын юып төшерергә, буфетка юнәләләр. Буфетчы апа салкын сырага чәйнектә кайнаган кайнар су кушып бирә. «Их, өйдәге хатын да шундый булса иде», – дип хыялланып та ала кайберәүләр.

Бер абзыйга сырасы, гадәттәгечә түгел, салкын кебек тоела һәм буфетчыга кружкасын суза: «Мә, апа, тагын бераз кушып җибәр әле», – ди. Буфетчыдан исә: «Кушыласы кушылган, берәзгәләмичә генә эчүеңне бел», – дигән җавап ишетә. Вагон бушатучы абзыйлар бу хәлне авылдашларга да сөйлиләр һәм безнең Кукмара төбәгендәге Мәмәшир авылында, нинди генә эчемлек булса да, «берәзгәләмичә эч» дигән әйтем кулланышка керә.

Рәйсә ГАЛИМУЛЛИНА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле.
Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга да соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

ЧАҢГЫ ЮЛЛАРЫ

Арча педагогия училищесында укый башлавымның беренче көне. Актлар залында үткәрелгән зарядка тәмамлануга, сәхнәгә җитез генә бер укытучы чыгып басты. Сүзе бик кыска булды:

– Әгәр арагызда чаңгы спорты белән шөгыльләнергә теләүчеләр булса, сәгать 4кә стадионга төшегез.

Бу – чаңгы секциясе җитәкчесе Ягъфәр Шәмиев иде. Күз алдында ничек пәйда булса, шундый ук тизлектә каядыр китеп тә барды ул. Акрын гына кабинетларга таралыштык. Минем эчемә корт кереп калды. Стадионны да күрәсе килә, чаңгыда шуарга да бик яратам. Мәктәптән кайтып, дәресләрне карап, әткәйгә булышкан арада күрше урамда яшәүче сыйныфташым Сәйдәш хәзер килеп җитә иде. Куып тота алмасам да, бик калышмыйм, җил куып, Лашчы станциясенә кадәр йөгерәбез.

Стадионга үзем генә төшәргә уңайсызландым, теләгемне дус кызыма җиткердем. Спорт киеме юклыкны сәбәп итеп, каршы төште. Миндә ике костюм, берсен биреп торам дип, көчкә күндердем үзен.

Без төшкәндә, секция эше башланган иде инде. Укытучы, безнең янга килеп, кайсы районнан икәнлегебезне белеште дә, берничә күнегү күрсәтеп, башкалар янына китеп барды. Күнегүләрне тәмамлагач, футбол уйнап алдык. Инде кайтырга чыгып, өскә күтәрелә башлагач, туп тау астына тәгәрәп китте. Укытучы, борылып: «Буа кызы, тупны алып менәрсең», – дигәч, туп артыннан йөгердем һәм… адашып калдым. Кайсы урамнан китәргә дә белмим. «Кара моны, әйләнеп тә карамый!» – дигән тавышка борылып карасам, таудан зәңгәрсу футболка кигән, дулкынланып торган сары чәчле бер егет төшеп килә. «Бу сукмак туры училищега чыга», – дип чакыргач, ияреп мендем инде.

Чаңгы секциясенә йөрүем шулай башланды. Күпмедер шөгыльләнгәннән соң, кулларга чаңгы таяклары алдык. Их, ошый да иде миңа тауга күтәрелү буенча эшләнгән күнегүләр! Әйтерсең лә син – кош, канатларың урынында – таяклар, ә үзең очасың, менеп җиткәнеңне сизми дә каласың. Берничә дәрестән соң мине тренерыбыз өлкән курсларда укучы кызлар төркеменә кушты. Абдуллина Суфия, Сабирова Эльвирадан күп нәрсә өйрәндем. Кызлар белән хәзер дә аралашып яшибез.

Ягъфәр Зыятдинович физкультура укытучысы буларак та, чаңгы спорты тренеры буларак та һәр дәресне теоретик белем бирүдән башлый иде. Шулай итеп, ул безне зур тормышка әзерләгән икән. Аның методикасы да, дәрес үткәрү технологиясе дә

бер-берсеннән нык аерылып торды. Кайвакыт өйрәнеп бетергән күнегүләр дә килеп чыкмый, кәеф тә төшеп китә, ә Ягъфәр Зыятдинович: «Через не могу эшләргә кирәк», – дип, көч өстәп җибәрә. Тормыш юлын узганда, мин бу сүзләрне бер дә онытмадым. 38 ел буена укытучы булып эшләгәндә дә, өч бала үстергәндә дә кулландым.

Тора-бара укытучыбыз чаңгы спорты секциясенә йөрүчеләр өчен иртәнге зарядка уйлап тапты. Нәкъ иртәнге сәгать алтыда паркка йөгерәбез. Саф һава, иртән күнегүләр дә хатасыз эшләнә. Тагын шул ягы да яхшы булып чыкты: син зарядкадан кайтасың, юынасың, иптәшләрең әле тормаган, аларның күзләре ачылмый, ә синең һәр күзәнәгең уянган. Шуннан файдаланып, ярты сәгатьләп дәресләреңне карап аласың, билгеле инде, бик яхшы җавап та бирәсең.

Беренче уку көненнән башлап шөгыльләнү бушка китмәде. Башта икенче-өченче урыннар белән генә канәгатьләнсәм, әкренләп нәтиҗәләр күрсәтә башладым. II курста Арча районы буенча I урын алдым, педучилище чемпионы булдым, республика күләмендәге ярышларда призлы урыннар яуладым. Боларның барысы да Ягъфәр Зыятдиновичның хезмәт җимешләре иде. Россия күләмендәге ярышларга да курыкмыйча бара идек без. Горький шәһәрендә РСФСР Мәгариф министрлыгы оештырган зона чаңгы ярышларында өченче урын яуладык. Дөрес, беренче урын түгел инде, ләкин без физкультура укытучылары әзерләүче педучилищелар белән ярыштык бит. Без укыган чорда Арча педучилищесында андый бүлек юк иде. Соңрак тренерыбыз анысын да оештырды.

Ягъфәр Зыятдинович безнең төркемдә II курстан башлап физкультура дәресләре һәм югары курсларда физкультура методикасы курсын алып барды. Бала күңелен нинди алымнар кулланып ачарга, нинди уен аша күнекмәләр бирергә, дәрестә ниләр белән җәлеп итәргә, сәламәтлек паузалары, күзләр өчен зарядка, бармаклар өчен гимнастиканың нинди формада отышлы булуын аңлатып, бездән чын укытучылар тәрбияләде ул.

Ягъфәр Зыятдинович бер яктан бик таләпчән, энергиясе, активлыгы ташып торган укытучы иде. Хыялыйлыгы да юк түгел иде. Әле генә баян уйный, ул ара булмый, спортзалга ияреп килгән кызы Диләрәнең шахмат фигураларын туздырып ата, күп тә үтми, чаңгы базасында безнең саксызлык аркасында ватылган, җимерелгән инвентарьны рәтли. Мин шул вакытларда бәләкәй Диләрәнең шахмат фигураларын тиз генә тезеп куеп, уйнарга маташуына шакката идем. Безгә яхшы үрнәк булып, әти тәрбиясенең нинди булырга тиешлеген дә аңлаткан икән.

Без эшләгән чорда берничә реформага, үзгәрешләргә эләктек. Шул чакларда Ягъфәр Зыятдиновичның нык характерлы булырга өйрәтүләре бик ярдәм итте. Дәресләрдә дә, дәрестән тыш вакытларда да иҗади эшләүче мәктәп коллективыбыз, «Матур мәктәп», «Мәктәп – сәламәтлек территориясе 2008» программасын гамәлгә ашырып, бер уку елында «Алтын дәрәҗә» таныклыгын алды, икенче уку елында «Мәктәп – сәламәтлек территориясе» республика конкурсында беренче урынга чыкты. 2008 елның ноябрь аенда «Сәламәт буын – сәламәт Россия» темасы буенча Мәскәүдә Бөтенроссия мәктәпләре съездында катнаштык.

Бу арада Ягъфәр Зыятдинович тагын да яшәреп киткәндәй булды әле. Бик күркәм юбилеен каршы алырга хәзерләнә ул быел. Аңа күңел тынычлыгы, үзе чәчкән белем орлыкларының уңдырышлы туфракта шытып, гел мул уңыш бирүен, акыллы үгет-нәсыйхәтләре белән безнең арада озын-озак яшәвен телибез.

Фәния ҖИҺАНШИНА-ХӘБИБУЛЛИНА,
1976 елгы чыгарылыш укучысы.
Буа районы Күл Черкене авылы

Мостаев җыры

Казандагы Чехов базары янында бер кафе бар иде. Заман рухындагы, күңелгә ятышлы, җыйнак бер кафе. Монда ризык мулдан: токмачлы аш, чүлмәктә пешерелгән шулпалы ит, кыздырылган тавык, бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, пәрәмәч… Барысы да тәмле, йөрәккә ята. Шулай да кафенең «бренд»ы – кыздырылган балык. Әллә нинди ят балык ул. Үзе карпка охшаган, әмма карп түгел. Диңгез балыгы. Кабыгы тоташ куба. Ите кучкыл, бик майлы, йомшак. Сезнең андый балыкны беркайда ашаганыгыз юк.

Бирédә еш кына элеккеге түрәләрне, партноменклатураны очратырга була иде. Алар барысы да диярлек шушы тирәдә тора. Якында гына – халык телендә «обкомская» дип йөртелгән «спецбүлнис». Өлкән кеше анда бармый торамы?! Башта алар бүлниска килә. Табибка күренә, шунда ук дару-мазар ала. Очрашалар, сөйләшәләр. Заманында җир җимертеп йөргән, күз өстендә каш булган, хәзер инде өй саклап ятучы картларга әңгәмә тансык. Сораулар күп. Кемнең кай җире авырта? Кем ничек йоклый? Йоклый аламы? Кичен саф һава суларга чыгамы? Сүзләре бүлнистән чыккач та бетми. Ә нигә юл өстендәге шушы кафега кереп утырмаска, әңгәмәне дәвам итмәскә?! Пенсияләре әйбәт, акча бар. Очрашу хөрмәтенә нигә бер йөз грамм коры шәраб тотмаска?! Җәйге эссе көннәрдә салкын сырадан да баш тартмыйлар. Анысын чикләвек белән уртлап утырырга ярataлар.

Берсендә шулай җәйнең бер эссе көнендә кафега шагыйрь Илдар Юзеев белән кердек. Кояш рәхимсез кыздыра. Исәбебез – берәр бокал салкын сыра алып, сөйләшеп утыру. Керсәк, «яшьти»ләр түгәрәкләнгән. Үзләре бер «дәүләт» булып утыралар. Нишләп «дәүләт» булмасын?! Аны саклаучы бар – өстәлнең сул ягында утырган абзый заманында обкомның оборона бүлеге мөдире булган. Киендерүче бар – җиңел промышленностьның экс-министры. Гүзәл белән Наташа ашаталар. Өстәлнең түрендә исә башын артка ташлап, ара-тирә горурлык белән як-ягына карап алучы, чама белән генә елмаеп куючы шәхес – бу дәүләтнең закон чыгаручысы. Ул – заманында ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе булып эшләгән Шамил Әсгать улы Мостаев. Бу «дәүләт»нең дөньясы түгәрәк – бөтен шартлар бар. Бер итекче генә кирәк бу «дәүләт»кә. Шулай дип уйлап кына куйдык, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасының элекке директоры (хәтерем ялгышмаса, Кыямов бугай) кафега килеп керде һәм шушы табынга килеп утырды. Болай булгач, бүреләре улый инде, дип көлешәбез. Уласын! Бу «дәүләт»нең килер җирен киң кыл, Ходаем.

Күңелләре дә киң икән. Кафеда очрашырга туры килсә, алар безне үзләре янына утырырга кодалый башлый. Күңеле тоташ шигърияттән торган, шаян-тапкыр сүзне бик урынлы әйтә белгән Илдар Юзеевны тагын каян табасың?! Ханнар да бит үз сарайларында шагыйрьләр, мәзәкчеләр тоткан. Башка язучылар һәм сәнгать әһелләренең дә бу «дәүләт»нең хозурында булганы бар.

Өлкәннәр табында ни турында сөйләшәләр? Хәлбуки сүз үткәннәрне сагыну тирәсендә бара. Мостаев күптән түгел генә үлеп киткән хәләл җефетен сагына. Кайчан гына очрашсак та, ул аны искә алмыйча калмый. Аны искә алганда, Шамил аганың күзләре дымлана, яшь тибеп чыгарга тора. Ул беравык сүзсез тора, аннары үзен бик тиз кулга ала һәм сөйли башлый. Мостаев – безнең табынның (табын ук түгел инде, өстәл) тамадасы. Сүзнең мәгънәсен югалттырмыйча, сөйләшү агымын бер көйгә агыза белә.

Үткәннәрне сагыну дигәннән, Шамил Мостаев Апаста да эшләде. Партия райкомының беренче секретаре иде. Димәк, районның хуҗасы. Берсендә шулай аз-маз сыра йоткалап, капкалап утырганда, Апас районында булган бер вакыйганы сөйләде ул: «Урак өсте. Дәүләткә ашлык чыгару планын үтәр өчен, кылны кырыкка ярырдай булып йөргән чак. Бер авыл икмәкне бирми генә бит. Председатель дә, районнан килгән кешеләр дә берништи алмыйлар. Кич белән тоттым да үзем киттем бу авылга. Китәр алдыннан, өйгә кереп, гармунымны алдым. Авылга килеп җитүгә, туп-туры ындырга. Караңгы төшеп килә иде. Ындырда эш гөрли. Уборкада төн уртасына кадәр эшләү бит инде. Барысы белән дә исәнләштем. Бу авылның холкын беләм, боларны сүксәң дә, үгетләсәң дә, баш бирмиләр, үзләренчә эшлиләр. Татарлар да, чуашлар да яши анда. Мин менә нишләдем: гармунымны алдым да көшел, көшел генә түгел, икмәк тавы түбәсенә менеп утырдым. Гармун уйный-уйный җырладым. Чуашча да, татарча да. Шул төнне үк элеваторга олау-олау икмәк озаттылар».

Бүген аларның күбесе, шул исәптән Шамил Мостаев та мәрхүм инде. Кафе бинасына кибет китереп тыктылар һәм кафены бер почмакка кысрыкладылар. Бүген мин анда кермим. Шәхесләр юк анда хәзер. Иң аяныч – «дәүләт» юк. Дәүләт булмагач, кызык түгел.

Вакыйф НУРИЕВ

«Татар-информ»

Тарихи мөмкинлек

Изге күргәзмә

Ике көндә 30 меңнән артык кеше! Болгарның Истәлек билгесе бинасына Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең ядкәрләре белән танышу өчен әнә шулкадәр кеше килгән. Хәзинәләрне күрергә теләүчеләр күп булу сәбәпле, күргәзмәне тагын ике көнгә озайтырга булганнар. Дагыстаннан кайтарылган ядкәрләрне дүшәмбе һәм сишәмбе көннәрендә башкаланың Кол Шәриф мәчетенә килеп күрергә мөмкин.

Оештыручылар ялгышмады ...

Оештыручылар яшерми: пәйгамбәрләребезнең ядкәрләре халыкта шулкадәр зур кызыксыну уятуга үзләре дә шаккаткан. Изге Болгар җыены көнне халык аларны карарга чират торган. Болгар шәһәренә эш сәфәре кысасында әлеге ядкәрләр белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та танышты. Ул Дагыстан Республикасы мөфтиенә рәхмәт белдерде, шулай ук күргәзмәнең уникальлеген һәм аерым кыйммәтен билгеләп үтте.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов Татарстанга Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең ядкәрләре кайтарылуны тарихи вакыйга дип атый.

– Тарихыбызда мондый күренеш беренче мәртәбә. Пәйгамбәребезгә һәм аның сәхабәләренә кагылышлы ядкәрләр аша халкыбызның күңеле тагын да нечкәрер, бердәмлегебез тагын да артыр, алар аша Аллаһы Тәгалә җөмһүриятебезгә дә, Ватаныбызга да бәрәкәт иңдерер дип өметләнәбез, – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Татарстан Рәисе ярдәме белән оештырылган күргәзмәдә Мөхәммәд пәйгамбәр, аның гаилә әгъзалары һәм сәхабәләренең кыйммәтле әйберләре урын алган. Экспонатлар арасында пәйгамбәрнең чәче, кылычы һәм касәсе, пәйгамбәрнең хатыны Гайшәнең чүлмәге, пәйгамбәрнең кызы Фатыйманың чүлмәге һәм кул тегермәне, Кәгъбәнең кара ташы, сәхабә Билалның чүлмәге һәм башка ядкәрләр бар.

Дагыстан мөфтие урынбасары Мөхәммәдрасул хаҗи Саадуев сүзләренә караганда, хәзерге вакытта сакланган дини ядкәрләрнең бер өлеше генә әле бу. Моңа кадәр алар, нигездә, гарәп ярымутравында яшәүчеләрнең шәхси коллекцияләрендә сакланган. Әлеге ядкәрләрнең күргәзмәсе Дагыстанда үткәндә, аны карарга бик күп халык агылган. Җирле халыкның дини хәзинәләребезгә шундый мөнәсәбәтен күргәч, әлеге ядкәрләрне үзендә саклаучылар аларның бер өлешен Дагыстанда калдырырга булган. Аларны Татарстанга кояш нурлары үтеп керми, махсус температура саклана торган сейфларда кайтарганнар.

– Әлеге ядкәрләрне күрергә шулкадәр күп кеше килү халыкның динебезгә булган мөнәсәбәтен бик ачык чагылдыра. Мөселманны Аллаһы Тәгалә, пәйгамбәребезгә булган мәхәббәте йөртә, бу аны динебезгә бәйле һәр нәрсә белән кызыксынырга, аны сакларга этәрә, – ди Мөхәммәдрасул хаҗи Саадуев.

Кол Шәриф мәчетенә дини ядкәрләр белән танышырга килүчеләр арасында Россия Дәүләт Думасы депутаты һәм синхрон йөзү федерациясе вице-президенты Ольга Павлова да бар иде. Пәйгамбәрнең хатыны белән кызының шәхси әйберләре аеруча ошаган аңа.

– Бу – бер Татарстан, мөселманнар өчен генә түгел, барлык традицион дин вәкилләре өчен дә мөһим вакыйга. Патриарх Кирилл бу экспозицияләрне бик ошатты. Россиянең көче – аның тарихында, традицион конфессияләрендә. Бүген барлык дин вәкилләренең башкарган һәр эше – безнең зур көчебез. Россия зур җиңү өчен берләшә. Күпләр безне таркатырга маташса да, аларның бу эшләре барып чыкмаячак, – ди ул.

Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең ядкәрләре тәкъдим ителгән күргәзмә дүшәмбе-сишәмбе көннәрендә Кол Шәриф мәчетендә иртәнге сәгать уннан кичке сәгать җидегә кадәр эшләячәк. Оештыручылар әлеге тарихи мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска киңәш итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ФӘНИТ ХАРИСОВ:

«БЕЗДӘ УКУЧЫ – БЕРЕНЧЕ УРЫНДА»

Казанның Бишбалта бистәсендәге 15 нче татар гимназиясе оешуга быелтыр 30 ел тулды.

Уку йортының җитәкчесе, Татарстанның атказанган укытучысы, педагогика фәннәре кандидаты Фәнит ХАРИСОВ белән туган телгә мөнәсәбәт, милли үзаңны үстерү һәм мәгариф проблемалары турында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Фәнит Фәхразович, сез – гимназиянең ишеген беренче булып ачып кергән директор. Шушы вакыт эчендә нинди үзгәрешләр булды?

– Бу бинада вертолет заводының училищесы урнашкан иде. Аны татар гимназиясе итеп үзгәрттек. Беренче тапкыр ишекне ачып кергәндә, куркып киттем, балаларга белем бирү өчен бернинди шартлар да тудырылмаган: гимназиядә салкын, ашханәсе юк, түбәдән су ага, идәннәре дә тузып беткән иде. Иртән килүгә, я торба шартлаган, я канализация тыгылган була. Балаларга татар телендә белем бирү теләгем зур булганга, кире борылмадым. Яшь идем, көч бар иде. Биш ел эчендә гимназиядә белем һәм тәрбия бирү өчен, тиешле шартлар тудыруны үземә максат итеп куйдым. Һәм без моңа ирештек.

Узган гасырның туксанынчы елларында милли үзаңны үстерү яңа сулыш алды. Ул чакта Казанда нибары бер генә татар мәктәбе бар иде. Ике телне дә камил белгән укытучылар таптык. Беренче елны безгә эшкә 11 укытучы, укырга 83 бала килде. Шартларның кыенлыгына карамыйча, балаларын туган телдә укытырга биргән әти-әниләргә рәхмәтлемен. Укытучыларның берсе дә шушындый киң колачлы эштән куркып калмады. Бергәләшеп, татар мохитен булдырдык. Хәзер гимназиядә барысы 437 бала укый, 33 укытучы аларга белем һәм тәрбия бирә.

:: Башка мәктәп һәм гимназияләрдән сез кайсы ягыгыз белән аерылып торасыз?

– Безнең гимназиядә өйдәге кебек мохит урнашты. Без гаилә кебек бердәм яшибез. Һәр баланы якыннан беләбез, игътибар үзәгенә алабыз һәм аңа шәхес итеп карыйбыз. Гимназиядә информатика, робототехника, музыка, спорт һәм башка юнәлештәге түгәрәкләр эшли, театр балаларның талантларын үстерергә ярдәм итә. Сәнгать мәктәбендә курайчылар ансамбле бар, укучылар тальянда да уйнарга өйрәнә. Безнең өчен балаларның мәктәптән тормышка өйрәнеп чыгуы мөһим. Егетләр чүкеч һәм пычкы да тота белергә тиеш. Спорт буенча да уңышларыбыз югары. Балаларның сәләтен вакытында күрмәсәң, шартларын тудырмасаң, ул бит үсә алмый. Геология һәм Бишбалта бистәсе көнкүрешен өйрәнү музейларын ачтык. Укучылар арасында КФУның геология факультетына керүчеләр шактый. Казан дәүләт энергетика университеты белән бик тыгыз элемтәдә эшлибез. Күптән түгел 500 мең сумлык грант откан идек. Ул акчага Хәсән Туфан исемендәге милли лаборатория булдырдык. Анда фәнни конференцияләр үткәрәбез, укучылар проектлар яклый. Татарча яхшы белгән, гимназия тормышында актив катнашкан балаларга милли җанлы Гарәфетдин әфәнде Хисаметдинов инде 11 ел дәвамында үзенең грантын бирә.

:: Илебездә тел сәясәте 2017 елдан бирле зур үзгәрешләр кичерә. Программаларда сәгать саннарындагы үзгәрешләрне ничек хәл иттегез?

– Татар теле дәресләрен нигездә шул ук күләмдә калдырырга тырыштык. Башлангычта туган телне дүртәр-бишәр сәгать укытабыз. Югары сыйныфларда гына бераз кимрәк. Укытучылар да башка эшкә күчмәде.

:: Татар теле кирәкми, диюче әти-әниләр дә бар хәзер...

– Бездә андый сүзләрне әйтүче юк.

:: Татар мәктәбе булгач, барысы да татарча булырга тиешме?

– Гимназияне ачканда, бар фәннәр дә татарча алып барылды. Бердәм дәүләт имтиханы кертелгәч, балаларны рус мәктәбенә ала башладылар. Үзегез беләсез: әти-әни бит ул баласы имтиханны яхшы бирсен дип тырыша. Шуңа күрә математика, физика кебек төгәл фәннәр русча алып барыла. Гимназиягә закон нигезендә яшәү урыны туры килгән балалар гына алынырга тиеш. Бишбалта бистәсендә яшәүчеләрнең 60 проценттан артыгы – руслар һәм башка милләт балалары. Шуңа күрә ике телдә укытырга туры килә. Әмма без татар мохитен сакларга тырышабыз, тәрбия эшләре татар телендә оештырыла. Татар телен өйрәнәбез дип килә бит алар. Барысы да татар телен сайлап, гариза яза. Берсе дә, кирәкми дип, бәхәсләшми. Теләүчеләр бик күп, әмма уку кабинетлары җитмәгәч, аларның барысын да ала алмыйбыз шул.

:: Дәреслекләр катлаулы, балаларга өй эшләрен эшләргә булыша алмыйбыз, диюче әти-әниләр дә бар. Бу проблеманы ничек хәл итеп була?

– Татар телен кухняда сөйләшү теленә генә калдырырга ярамый. Туган телдә дөрес, аһәңле итеп сөйләшергә өйрәтү белән бергә тиешле күләмдә теоретик мәгълүматны бирмичә ярамый, чөнки ул – укучының туган теле. Саф татар теле югалырга тиеш түгел. Белем дәрәҗәсенә карап, без сыйныфларны икегә – яхшырак һәм йомшаграк белүчеләргә бүлеп укытабыз. Болай эшләүнең максаты – барлык балаларга да тигез күләмдә һәм сыйфатлы белем бирү. Бу уңайдан төрле тәҗрибәләр уздырып, анализ ясыйбыз һәм гамәлгә кертәбез.

:: Татар мәктәбендә укып та, зур уңышларга ирешеп була, дигәнне тагын бер кат искә төшерик әле. Сез дә – дүрт бертуган Харисовлар – татар мәктәбен тәмамлаган кешеләр бит.

– Без – Фираз, Фарис, Фәнит, Фәрит Башкортстанның Яңавыл районындагы Истәк авылыннан. Барыбыз да татар мәктәбен, аннан Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлап, гомеребезне татар мәгарифен үстерүгә багышладык. Фарис 1997–2004 елларда Татарстанның мәгариф һәм фән министры вазыйфасын үтәде. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши. Россия Мәгариф академиясе әгъза-корреспонденты, шунда эшли. Фираз Харисов – күп еллар буе Казан педагогика университетында проректор, хәзер КФУның татар теле белеме кафедрасы профессоры. Ике абый да – фән докторлары. Фәрит энем Башкортстанның Яңавыл шәһәрендә күп еллар буе гимназия һәм 1 нче мәктәпне җитәкләде. Татар телендә белем алган кеше беркайчан да тормышта югалып калмый.

Сәрия МИФТАХОВА

ЭШ КАРТАЙТМЫЙ

mtsz.tatarstan.ru

Яшәргә өйрәнәбез

Замана өлкәне. Ул хәзер башкача яши. Аларны әби-бабай дип тә булмый. Араларында апа дигәнне кабул итмәүчеләр дә бар. Хикмәт яшьтә түгел, ди алар. Күңелләре һаман унсигездә. Яшьләрдән дә калышмыйлар. Һәрхәлдә, тырышалар. Интернетны беләләр, тырнак, керфек ясаталар, матур итеп бизәнәләр. Хәтта башкаларны да бизиләр.

Сүзем – олыгаеп барганда һөнәр алыштыручылар турында. Күптән түгел бер матурлык салонында чәч кисүче ханым белән таныштым. Луизага – 58 яшь. Гомере буе заводта эшләгән. Моннан өч ел элек эшендә кыскартуга эләккән. Инде нишләргә дигәндә, җитәкчесе, синең кебекләрне дәүләт бушка укыта, дигән яңалык җиткергән.

– Башта бик авыр булды. 35 ел буе бер урында эшләдем бит. Пенсиягә дә чыга алмадым дип уфтандым. Хәтта утырып еладым да. Тик яшь түгеп кая барасың… Тоттым да икенче һөнәргә укыдым. Дөресрәге, укыттылар. Хәзер сөенеп туя алмыйм. Бу эшем шулкадәр ошый. Көн саен төрле кешеләр белән аралашам. Рәхмәт сүзләре ишетәм. Тик утырмыйм, яңадан-яңа курслар үтеп, тәҗрибә туплыйм. Бер начарның бер яхшысы була, диләр бит әле. Ярый әле теге эштә кыскартканнар, – ди Луиза.

Аның кебекләр күп. Казанда яшәүче Мөршидә Сәгыйтова берничә ел элек тегү ательесы ачкан. Ул да, элек эшләгән җирендә кул хезмәте автоматлаштырылгач, эшсез калган була. Бәхетенә, тегүчелеккә укый.

– Коронавирус башланган вакыт иде. Башта өйгә кайтарып җибәрделәр. Аннан ике ай узгач, эшсез калуымны әйттеләр. Мин дә бушлай укыдым. Өйдә ир-егетләрнең чалбар балагын гына бөккәнем бар иде. Хәзер инде әллә ниләр тегә беләм. Киемне сатып та алмыйбыз. Барысын да үзем эшлим, – ди Мөршидә ханым. – Солдатларга кирәк-яракларны да күп тектем. Аларга ярдәм итә алганыма да сөенәм. Үз улым да махсус хәрби операциядә бит. Ничекләр булышмыйсың? Яшьрәк чакта тегүчелеккә укыйсы калган, дим.

Чаллыда яшәүче 54 яшьлек Эльмира Гарифуллина хатын-кызларга маникюр ясый. Ул да эшсез калган. Бер мәктәптә татар теле дәресләре укыткан булган. Дәрес саннары кыскартылгач, матурлык өлкәсен сайлаган.

– Мәктәбемне, балаларны бик сагындым башта. Хәзер инде яңа һөнәремә ияләштем. Шулкадәр рәхәт итеп эшлим. Күңелне тынычландыра торган эш. Кызым да кешеләргә тырнак ясый. Белмәгәнне ул өйрәтә, – ди Эльмира.

Арчада яшәүче Илшат Ибраһимов та башта эшсез кала. Күп уйлап тормый, икенче белем ала. Аннары исә үз эшен ачып җибәрә. Яшелчә үстерәләр икән. Үз-үзеңә хуҗа булып эшләү рәхәт, ди ул.

Пенсия яшенә җитүче яңа һөнәр алырга теләүче кешеләр кая барырга тиеш? Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сүзләре буенча, яңа һөнәр алырга теләүчеләрне «Демография» илкүләм поекты кысасында бушлай укыталар.

– Республикада 50 яшьтән өлкәнрәкләргә өстәмә һөнәри белем бирү каралган. Алар моның өчен «Россиядә эш» («Работа в России») платформасында теркәлергә һәм, үзләре яшәгән районның мәшгульлек үзәгенә барып, гариза язарга тиеш. Гариза язганда, һәр кеше үзенә кирәкле һөнәрне сайлап ала, – ди ул.

Татарстанда хәзерге вакытта 280 белем бирү программасы буенча укыталар. Алар арасында IT, аналитика, программалаштыру, идарә итү, менеджмент, маркетинг, финанслау, дизайн, эшмәкәрлек һәм бизнес, сервис һәм хезмәт күрсәтү өлкәләре дә бар. Укытып чыгаргач, яңа һөнәр алучылар эшкә дә урнаштырыла. Кайберләре үзләре эшләгән оешманың башка бүлегенә дә күчә. Яңа һөнәрләргә укыган кешеләр арасында шәхси эшмәкәр булып теркәләләр, крестьян-фермер хуҗалыгы ачалар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

«Демография» илкүләм проекты ярдәме белән **2020** елда **9173** кеше икенче һөнәр алган. Шуларның **1687**се – **50** яшьтән өлкән, **62**се – пенсия яшенә җитеп килүчеләр. Быелның май аенда алынган мәгълүматлар буенча, **1486** кеше укырга кергән. Яңа һөнәргә өйрәнүчеләр арасында декрет ялында утырган әниләр дә бар.

Спорт

КАЙТТЫЛАР

«Рубин» премьер-лигага әйләнеп кайтты. Калининградта җирле «Балтика»ны откан Казан командасы турнир таблицасында беренче урынга күтәрелде. Калган ике очрашу ничек кенә тәмамланса да, Рәшит Рәхимов уенчылары киләсе сезонда иң көчлеләр белән ярышу мөмкинлеген кулдан ычкындырмаячак.

Узган елның 21 маенда «Рубин», үз кырында узган хәлиткеч матчта «Уфа»га оттырып, беренче лигага төшкән иде. Быелның 20 маенда исә кабат премьер-лигага чыктылар. Нәкъ бер ел узды. Футболчылар ел буе тамашачыга «бергә кайтабыз» дип вәгъдә бирсә дә, моңа ирешү җиңел булмады. Беренче лиганың иң яхшы уенчылары чыгыш ясаган командада ике мәртәбә тренер алмашынды. Башта Леонид Слуцкий китеп барды, аның урынына килгән Юрий Уткульбаев та озак тоткарланмады. Баш тренер вазыйфасына Рәшит Рәхимов билгеләнгәч кенә Казан командасы беренче лиганың лидерына килешерлек уен күрсәтә башлады. Ул килгәнче рәттән 4 очрашуда ничьяга уйнаган «Рубин» соңгы 6 матчта җиңүгә иреште. Тренер алмашыну аркасында гына түгел бу. Команданы кабат иң көчлеләр сафына кайтару өчен, Казан клубында җитәкчелекне алмаштырырга, идарә итү, хәтта ки фикерләү рәвешен үзгәртергә туры килде.

Узган атна ахырында Калининградта узган очрашу аерым игътибарга лаек. Ник дигәндә, җирле «Балтика», бу сезонда нибары бер мәртәбә оттырып, узган җәйдән бирле турнир таблицасында беренчелекне кулдан ычкындырмады. Рәшит Рәхимов уенчылары 1:0 исәбе белән көндәшне отып, беренче лигада кемнең иң көчле булуын раслады.

Бу сезонда Казан командасының тагын ике уен уздырасы калды. Ул очрашулар ничек кенә тәмамланса да, «Рубин» турнир таблицасында икенче урыннан аска төшмәячәк. Шуңа күрә клуб җитәкчелеге ул уеннар түгел, инде хәзер киләсе сезон турында уйлана дип аңларга кирәк. «Премьер-лигага чыгучы командаларның составы 60–70 процентка үзгәрергә тиеш. Бу – бөтенләй башка дәрәҗә, башка каршылык һәм башка тизлек. Әмма анысының да ничек килеп чыгасын әйтеп булмый. Чөнки яхшы уенчы табу җиңел түгел. Әлбәттә, нindидер уенчыларны күзлибез, барлыйбыз. Әмма алар безгә килмәскә дә мөмкин бит әле», – ди баш тренер Рәшит Рәхимов.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

	Команда	уен	очко
1	Рубин	32	65
2	Балтика	32	64
3	Алания	32	56
4	Енисей	32	50
5	Родина	32	46
6	Динамо Мх	32	46
7	Волгарь	32	44
8	Шинник	32	43
9	Арсенал	32	41
10	СКА-Хабаровск	32	41
11	КАМАЗ	32	41
12	Нефтехимик	32	41
13	Акрон	32	40
14	Кубань	32	34
15	Велес	32	33
16	Уфа	32	32
17	Волга Ул	32	29
18	Краснодар-2	32	25

rubin-kazan.ru

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

МАРИ

Кукмара

ИРЕК

Мәҗбүриләп, бернигә дә ирешеп булмый. Һәр нәрсә буыннан-буынга тамырлар аша җиткерелә. Кукмара районының Починок-Кучук авылында яшәүче Мозаффаровларның үз асылларын саклап калу өчен алган кыйблалары әнә шундый. Моңа нинди юллар белән ирешмәкче алар? Без шул хакта сөйләштек.

Киләчәктә беләчәк

Починок-Кучук авылында яшәүче халыкның яртысы марилар булса, калганы – татарлар. Гомумән, җирлектә ике милләт халкы үзара дус-тату. 469 мари, 467 татар яши анда.

– Элек монда бары марилар гына яшәгән. 1967 елда күрше Красный Октябрь авылында зур янгын чыгып, йортларның күпчелеге көлгә әйләнгәч, татарлар безнең авылга килеп төпләнде, – дип сөйләде Маргарита Мозаффарова. – Дөрес, аңа кадәр дә без – татарлар белән бер колхозда эшләп, үзара аралашып, кунакларга йөрешеп яшәгән кешеләр. Бу яктан караганда, марилар – үзенчәлекле халык. Без бер генә милләтне дә, телне дә кире какмыйбыз. Кирәк икән – өйрәнәбез. Шул ук вакытта үзебезнең асылыбызны да җуймыйбыз. Безнең борынгы бабаларыбыз бу җиргә нинди йолалар, традицияләр, бәйрәмнәр белән килгән, шуларны булдыра алганча саклап калырга тырышабыз. Моның өчен зур рәхмәт аларга. Әлеге рухи кыйммәтләрне балам, оныгым да саклар, дип ышанам. Чөнки болар – аларның канында.

Авылда төрле милләт вәкилләре яшәгәч, катнаш никахлар – алар өчен гадәти күренеш. Әйтик, Мозаффаровларның кызлары Татьяна да татар егетенә кияүгә чыккан. Дөрес, тормыш иптәшен ул күрше Югары Арбаш авылыннан сайлаган. Шулай да күп вакыты төп йортта – әни-әнисе янында уза. Чөнки бирегә ул көн саен эшкә йөри. Кызы Ясминәне тәрбияләүдә дә әти-әнисе – төп таянычы.

Без килгәндә дә, Татьяна белән Ясминә әти-әнисе янында кунакта иде. Бөтерчек кебек кызчык та сүзгә тапкыр, терекөмеш кебек чая бала булып чыкты. Тик аралашуы гына рус телендә.

– Әлегә оныгыбыз рус телен сайлады, – диде Маргарита Захаровна, безнең сораулы карашыбызга җавап итеп. – Без телләрнең катышуын теләмибез. Балага марича сөйләшергә иртәрәк әле. Бераз вакыт узгач, ул аны үзе өйрәнәчәк. Мари телен дә, татарчасын да. Без моны тел чарлансын өчен эшлибез. Әгәр телләр бутала икән, сүзлек запасы аксый. Ясминә марича белмәс, дип һич кенә дә икеләнмибез. Ул бик тиз өйрәнәчәк.

Маргарита һәм Сергей Мозаффаровлар икесе дә – абруйлы укытучылар. Сергей Николаевичның 50 еллык педагогик стажы бар. Әле дә булса сафта ул. Балаларга физика һәм информатика фәннәреннән белем бирә. Маргарита Захаровна исә гомер буе башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән. Шуңа күрә тел өйрәтү мәсьәләсендә алар башкачарак фикердә тора.

– Гаилә әгъзалары бер милләттән булган очракта, телне бишектән өйрәтергә кирәк. Кызым катнаш никахта булганга күрә, оныгыбызга сайлау мөмкинлеге бирдек. Озак еллар укытучы булып эшләгәч, телләрне бутамаска кирәклегенә төшендем. Телләр катнашканда, балалар үз фикерләрен әйтә алмый. Сөйләм матур, камил килеп чыксын өчен, телләрне кушарга ярамый. Бер юнәлеш булганда гына балалар телне тиз отып ала. Ясминә татар теле белән дә кызыксына, мультфильмнар карый. Мари телен исә көн саен бездән ишетеп үсә. Ә русчаны әлегә аралашу теле буларак сайлады. Мари теленә тормыш аны үзе өйрәтәчәк, – ди Маргарита Мозаффарова.

Мозаффаровлар дога көченә дә бик нык ышана. Шуңа күрә аларның бер генә милли бәйрәмнәре дә дога кылмыйча, теләк теләмичә узмый.

– Телгә хөрмәт булсын, дисәк, рухи тәрбияне читкә куярга ярамый, – ди ул. – Миңа калса, һәр гаилә үз туган телендә әйтелгән доганың мәгънәсенә игътибар бирергә тиеш. Дога теле борынгы ул. Ул безнең колаклар өчен генә түгел, беренче чиратта күңел өчен кирәк. Үз туган телеңдә дога кылуның энергетикасы әйтеп бетергесез зур. Аларның эчтәлеге күңелгә сеңә, гаиләдә бала күңеленә тапшырыла икән, тел югалмас.

Әниләр балаларына әкиятләрне туган телләрендә укысыннар, бишек җырларын туган телләрендә җырласыннар иде, дигән теләген дә җиткерде.

– Телгә мәхәббәт бары тик гаиләдә салына. Мәктәптә ул ныгытыла гына. Туган телдә уздырылган чаралар да баланың күңеленә геройлар, җырлар аша сеңеп кала. Шулай да соңгы елларда мәктәптә дә балаларның рус телендә аралашулары проблемага әйләнеп бара, – дип сүзгә кушылды Сергей Николаевич. – Телне дәрестә генә укыту җитми. Ул көндәлек тормышта булганда гына сакланып кала ала. Мин физика дәресен укытканда, терминнарның марича аңлатмасына да игътибар бирәм.

Телне куркытмыйк

– Тел бетү мәсьәләсе бөтен милләткә дә хас. Ул кемне генә борчымый икән? Ләкин бу турыда кычкырып йөрүдән мәгънә юк, – дип саный Маргарита Мозаффарова. – «Балалар өйрәнми, тел бетә», – дип сөйләп торып, уңай нәтиҗәгә ирешеп булмаячак. Шул килеш гомер буе кычкырып утырырга була. Ул тел бетмәсен өчен, нәрсә дә булса эшләргә кирәк. Балаларны мәҗбүриләп тә, «менә болай эшләгез», «тегеләй итегез», дип гел әйтеп торып та уңай нәтиҗәгә ирешеп булмый. Бала күңеленә акрынлап сеңдерергә кирәк.

Маргарита Мозаффарова әйтүенчә, балалар күңеленә орлыкны гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр аша салырга кирәк.

– Балалар үз милләтенә бәйле гореф-гадәтләрне күрсәтергә кыенсына, – ди ул. – Ләкин кечкенә чакта күңелгә кереп урнашкан орлыклар, балалар үсеп, үз гаиләләре булгач, нәтиҗәсен бирәчәк. Укытучыларга киңәшем бар. «Минем тырышлыклар бушка китте, берни дә өйрәнмәделәр», – дип кәефне төшерергә кирәкми. Аларның бер бөртеге дә исраф булмый. Иң мөһиме: орлыкларның вакытында чәчелүе кирәк, алар барыбер үз шытымнарын бирәчәк. Ә боларның барысы да гаиләдә бирелә. Тел бетмәячәк, аны «бетә» дип куркытмаска гына кирәк. Әйе, оныгыбыз әлегә рус телен сайлады. Ләкин аңа карап, ул туган теленнән ваз кичмәячәк. Без моңа шикләнмибез дә.

Туган теленең киләчәге өчен кызлары Татьянаның да күңеле тыныч.

– Барысы да вак кына ышанулардан башлана. Безгә әти-әни кечкенәдән үк ырымнарны күңелгә сеңдереп үстерде. Йола, бәйрәмнәрне дә күреп, белеп үстек. Хәзер кызым да шулар ярдәмендә тәрбияләнә, – ди ул.

Изге алан

Мозаффаровлар милли бәйрәмнәргә зур игътибар бирә. Дөрес, еллар узу белән, кайберләренең тәртипләре үзгәргән, заманчалашкан, кайберләренең асыллары җуелган. Шулай да авылда ел саен Пасха, Раштуа, Май чабу, Питрау көннәрен билгеләп узалар. Раштуада сакланып калган ырым-шырымнары да бар.

– Элек бу бәйрәм тагын да күңеллерәк уза иде. Әйтик, төрлечә киенеп, авылны урап чыгыш иде. Әгәр сине танымыйлар икән, бөтен начарлык иске елда кала, энергетика алышына дигәнне аңлата иде. Шуңа күрә башкалар танымаслык итеп киенергә тырыштык. Хәзер аның тәртипләре бераз үзгәрде. Бер елны – бер авыл, икенче елда башка авыл кешеләре йорттан-йортка йөри. Менә инде ничә еллар шулай уздырабыз. Узган ел, мәсәлән, кешеләр безгә керделәр. Без каршы алдык. Бәйрәм, күргәзмә оештырдык, кунакларны мичтә әзерләнгән милли ризыклар белән сыйладык. Төрле боткалар, милли ризыклар, ярма һәм ит бәлешләре пешердек.

Биредә Май чабу бәйрәмендә тау шуу мәҗбүри булса, Пасха таганда атынудан башка узмый икән. Бу вакытта да энергетика яңара, гомер озыная, дип ышана марилар. Ләкин бар бәйрәмнәр арасында иң зуры – 12 июльдә үткәрелә торган Питрау көне – Сурем бәйрәме. Бу көнне изге аланга (кугусу) чыгып, корбан китерү гадәте хәзергә кадәр сакланып калган. Ул көнне бар халык: олысы, кечесе билгеле бер урынга чыгып, дога кыла, теләкләр тели, рәхмәт әйтә һәм корбан чала. Аны исә кемедер авырган яки якыны армия хезмәтенә киткән кешеләр чала. Терлек шул ук урында эшкәртелә, итеннән аш һәм ботка пешерелә. Бу йоланы башкарасы көн алдыннан мунча керергә, чистарынырга кирәк икән.

Кызыксыну

Починок-Кучук авылындагы урта мәктәптә төрле милләт вәкилләре – татарлар, марилар, руслар, удмуртлар, украиннар белем ала. Тышкы яктан мәктәп зур, иркен булып күренсә дә, бала саны күп түгел. 74 кенә укучы.

Директор урынбасары Алия Сәгъдиева сөйләвенчә, мәктәптә мари теле атнага өч сәгать укытыла. 2021 елда мәктәп, телләрне саклауга юнәлдерелгән проектларны үстерү өчен, 500 мең сум күләмендә грант откан. Ул акчага мари теле дәреслекләре һәм проекторлар сатып алганнар.

– Соңгы елларда балалар мәктәптә үзара рус телендә аралаша башлады. Ләкин без берничә ел балаларның үз туган телләрен популярлаштыру өстендә эшлибез. Шуңа күрә төрле чаралар уздырганда, туган телләрендә сөйләшүләрен сорыйбыз. Алар түгәрәкләргә, ансамбльгә йөри, – диде Алия Сәгъдиева.

Телне өйрәнүдә авырлыклар булмаса да, башка милләтләрдәге кебек, мариларда да дәреслек проблемасы бар.

– Балалар дәрестән соң үзара башлыча русча аралашса да, дәрестә туган телләрен яратып, кызыксынып өйрәнә, – ди мари теле укытучысы Ирина Родыгина. – Тел өйрәнүгә стимуллары бар. Без аларны, никадәрле күбрәк тел белсәгез, шулкадәрле бай булырсыз, дип тәрбиялибез. Төрле бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар алуга ирешәбез. Быел, мәсәлән, 9 нчы сыйныфта белем алучы укучым туган телләр буенча олимпиадада призер булды. Ә инде үзара русча сөйләшүнең төп сәбәбе интернетта, телефонда дип уйлыйм. Укучылар башта русча фикерли, шуннан соң гына туган телләренә күчә. Барыбер рус теле өскә калкып чыга. Шунысы сөендерә: үз туган телен өйрәтергә теләмәгән ата-аналар юк. Катнаш гаиләләрдә үскән балалар исә гаиләдә кайсы тел аралашу теле булып тора, шуны сайлый.

Башлангыч сыйныф укучылары өчен мари орнаментларын чигәргә өйрәтә торган түгәрәк тә эшләп килә. Без килгәндә дә балалар үзләренең осталыкларын чарлый иде. Укытучылары Валентина Юнысова әйтүенчә, укучылар мари милли бизәкләрен генә чигеп калмый, ә аларның нәрсә аңлатуын да өйрәнеп, белеп үсә. Әйтик, мариларның төп милли бизәге – кояш, имән агачы – табигать сакчысы, күгәрчен – мәхәббәт символы.

– Тәртип буенча, без анда ак киемнән барырга тиешбез. Шуның өчен мин махсус аксыл кием тектем. Олы Кугу Юмога (Бөек Ак Алла) теләкләр теләп, шуңа ялварабыз. Узган елдан башлап әлеге йоланың мәгънәсе тагын да артты. Безнең җирлектән махсус хәрби операциягә уналты егетебез китте. Алар юлга кузгалыр алдыннан, барыбыз да тиз арада җыелып, шушы йоланы башкардык. Шулкадәр күп кеше катнашты анда, хәтта үзем дә көтмәгән идем. Авылдашларыбызның сау-сәламәт әйләнеп кайтуын, дөньяга тынычлык килүен теләдек. Шәмнәр кабыздык, учак яктык. Ипи, тоз, су һәм куас та алдык. Авылдашларыбыз хәрби операциядән ялга кайткач та, шул аланга бардык. Егетләребезне шул догалар бүгенгә кадәр саклап йөртә. Мин бу чараны оештыручы кеше буларак, ир-атларыбыз каршында җаваплылык хисе тоям һәм һәр көн саен алар исәнлегенә дога кылам, – ди Маргарита Мозаффарова.

Ул әлеге йоланы моннан соң да яшьләр башкарачагына чын күңеленнән ышана.

– Мин үзем аны бөртекләп өйрәндем. Дөрес башкармасаң, гөнаһын кая куярсың? Үземә килеп сораган кешеләргә дә тәртипләрен яхшылап аңлатам. Ата-бабалар безгә калдырган икән инде, без дә белгәнебезне яшь буынга чәчми-түкми тапшырырга тиешбез. Шуңа күрә изге аланга яшьләрнең килүе аеруча сөендерә, чөнки ул йолалар барыбер аларның күңеленә сеңеп калачак, – ди ул.

Сәхифәне Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

ВИДЕО

Милли ризыклар

Мариларның дини бәйрәмнәрдә һәрвакыт әзерли торган ризыклары команмелна дип атала. Камыры кыстыбыйныкы кебек әзерләнә. Аны майсыз табада кыздырып, төс кертеп алалар, эчлеге йомырка, каймак, тоз, шикәр һәм май салып болгатылган эремчектән була.

– Пасхага кадәр сишәмбе көнне мунча ягып, ярмалар белән пироглар пешерәбез. Кырыйларын үреп чыгабыз. Пәнҗешәмбе көнне исә шәмнәр куеп, мәрхүмнәргә мөрәҗәгать итәбез, тормышыбыз бәрәкәтле булсын өчен, аларны «сыйлыйбыз». Тик без аларга: «Бары тик бәйрәмгә генә килегез, чакырмаган вакытта килеп йөрмәгез, безне борчымагыз», – дип әйтәбез, – ди Татьяна.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 271

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+